Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 42 (1458) 27 октябрь 2023 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga
madanizhomga
madani_zhomga

8-9

Фашистлар оясында яшерен оешмага Мари Элнең Бәрәнге авылында туган совет офицеры Гайнан Кормаш нигез сала.

12-13

Халык күңеленә сөекле һәм моңлы җырчы булып кергән Зифа Басыйрова 1937 елда ирсез генә калмаган, ул аннан соң да рәнҗетү-тип-кәләнүләрдән азат була алмаган.

14-15

Әтиләрен совет «хуҗалары» «кулак-ка» чыгарып төрмәгә озатканнан соң да ятим балалар ел-лар буе туем икмәк, хөкүмәт тарафыннан ипле караш күрми газап чиккән.



Гомеркәен моңнан үргән затлар
Әверелеп яшәр былбылга!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● 2024-2026 елларга массакүләм мәгълүмат чараларына республика бюджетыннан бүленеп биреләчәк акча кимиячәк.

● Минзәлә татар дәүләт драма театры коллективы Төркиянең Анкара каласында «Сөясеңме, сөймисеңме» спектаклен күрсәтеп һәм Истанбулның «Топкапы» мәдәни паркында театральләштерелгән концерт куеп, Татарстанга әйләнеп кайтты.

● Татарстанның Милли китапханәсендә Европа һәм Көнчыгыш цивилизацияләренең язмачылык тарихын чагылдырган күргәзмә ачылды.

● Чистайда татар дин белгече, Татарстанның беренче казые, XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы күренекле дин эшлеклесе, галим Габделхак хәзрәт Саматовка багышланган XI Саматов укулары узды.

● Палестина эшмәкәре Аласиби Зияд Курган өлкәсендә янган Йолдыз авылы кешеләренә ярдәм итте.

● Төркмәнстанда Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре узды.

● Казанның 93 нче гимназия территориясендә Александр Пушкинга һәйкәл һәм яңартылган «Пушкин скверы» ачылды.

● Татарстан Дәүләт Советы наркотиклар белән тотылган депутат Рөстәм Хәсәновның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатты, аның эше судка тапшырылды.

● Азнакай районының Октябрь Бүләк авылы 100 еллык юбилеен билгеләп узды.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

27 октябрь – актёр, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Раушан Тимерҗан улы Шәриповка 60 яшь (1963).

28 октябрь – шагыйрә, педагог Вәсимә Лотфулла кызы Хәйруллина (Талипова)га 80 яшь (1943).

29 октябрь – Татарстан Республикасының Олы Кайбыч авылында Галия Кайбицкая музее ачылуга 25 ел (1998).

30 октябрь – тарихчы, педагог Рифгать Шакирҗан улы Таһировның тууына 120 ел (1903–1977).

1 ноябрь – драматург, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Риза Фәхреддин улы Ишморат (Ишмоdu)ның тууына 120 ел (1903–1995).

СЫНАМЫШЛАР

● Октябрь япмаса, декабрь япмас ● Беренче кар көндез яуса – кыш салкын, төнлә яуса – җылы була ● Әүвәлге карны күрсәткәч, кырык көннән кар ятар ● Боз кытыршы булып туңса, иген уңар ● Әгәр кар җиде мәртәбә явып, җиде мәртәбә эреп бетеп, сигезенче тапкыр яугач ятса, киләсе җәйне ашлык бик уңар.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **6 сәгать 39 минутта чыкты**, һәм ул **16 сәгать 18 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **9 сәгать 39 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **30 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **3 ноябрьдә 9 сәгать 09 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Октябрь-ноябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 31 октябрь.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(29 октябрь – 5 ноябрь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген рабигъул ахир аеның 12 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Ибраһим Юнысов һәйкәлен кем җимергән?

Яңа татар зираты территориясендә XIX гасырдагы берничә мөселман кабер ташы җимерелгән. Шулар арасында меценат, иң бай татар сәүдәгәрләренең берсе Ибраһим Юнысов кабер ташы да бар.

Фото: © «Миллиард.Татар»

Без тикшерүне төп керү урыннан түгел, ә Меховщиклар урамы ягыннан башладык. Шунда ук каршыбызга XIX гасыр кабер ташлары белән татар зираты чыкты. Башта һәйкәлләрне махсус рәвештә кемнәрдер җимергәнен күрсәтүче берниндидә билгегә тап булмадык.

Зират эченә кергәндә, бер өлкән кеше Юнысов кабер ташының ватылу сәбәбе дип, килүчеләрдән ташның йөрергә комачаулавыннан зарлануын атады.

«Карагыз, монда аллеялар нинди киң. Монда машина йөри ала. Әгәр дә без монда борылырга теләсәк, безгә иске кабер ташлары түгел, ә монда тулы бер лабиринт барлыкка китерүче металл коймалар комачаулый», – дип зарланды әңгәмәдәшебез.

Төп аллея буйлап барганда, юл буенда ватылган кабер ташының кисәкләрен күрдек. Мәрҗани исемендәге Тарих институты хезмәткәре Айдар Гайнетдинов, ватылган кисәкләрне караганнан соң, кабер ташын XX гасырның 50нче еллары белән даталарга мөмкин, дип белдерде. Ул табигый факторлар тәэсирендә җимерелгәнме яки кемдер ярдәм иткәнме – аңлашылмый. Алга таба барганда, без тагын берничә ватылган кабер ташын күрдек.

Бистә татарлары арасында «Озын Ибрай» кушаматы алган Казан сәүдәгәре Ибраһим Юнысовның каберен табарга безгә Яңа Татар бистәсе каталогы ярдәм итте. Монда 1930 елларга кадәрге барлык кабер ташлары, шул исәптән Ибраһим Юнысов кабер ташының фотосы һәм аның урыны күрсәтелгән. Нәтиҗәдә, куаклык һәм койма лабиринтлары аша үтеп, без 20 нче участокка килеп җиттек һәм Юнысов каберен таптык.

Кабер 2 кв. метр мәйданны били. Юнысовның кабер ташы күрше каберлекнең коймасына таянганга күрә, аны сүтканнәр. Кабер өстенә куелган плитә җимерекләр өемене әйләнгән. Безне озата баручы Айдар Гайнетдинов плитә кисәген тапты, анда гарәпчә мәрхүм меценатның исеме һәм фамилиясенең беренче хәрефләре уеп язылган.

Шунысы сәер: ватылган ташлар янында 2 метр биеклектәге зур кабер ташы ята һәм нәкъ менә шушы ташның Ибраһим Юнысовныкы булуын күрсәтүче табличка бар. Димәк, башка кабер җимерелгән булып чыгамы?

Айдар Гайнетдинов, кабер ташын өйрәнгәннән соң, түбәндәге нәтиҗәгә килде. «Кабер ташына «Коммерция киңәшчесе Юнысов Ибраһим Гобәйдуллович» дигән табличка куелган. Бу табличка монда дөрес куелмаган, чөнки кабер ташы бөтенләй башка кешегә карый. Кабер ташының табличка урнаштырылган алгы өлешендә язулар беткән, әмма арткы өлешендә без «Маһруй Мөхәммәтҗан кызы» дигән язуны укый алабыз. Димәк, бу – хатын-кыз кабере. Бу табличка турында зират администрациясе беркем белән дә киңәшләшмәгән, һәм бу табличканы, кешеләрне бутамасын өчен, алып ташларга кирәк», – дип канәгатьсезлеген белдерде ул.

Чыгу өлешенә таба барганда, Гайнетдинов мондый кабер ташларын ничек саклап калырга мөмкин икәнлеге турындагы фикерләре белән уртаклашты. Төп керү урынындагы кабер ташларының берсе янында тукталып: «Кайбер матур кабер ташларын төп аллея буйлап урнаштыралар, шулай итеп, кешеләр зиратка кергәндә аларны күрә ала. Ни өчен Ибраһим Юнысов кабер ташын шулай урнаштырмаганнар, аның өчен урын бар бит», – диде.

Безнең экспедициянең соңгы ноктасы Яңа татар зираты администрациясе булды. Без татар меценаты кабер ташының ватылган калдыклары белән нәрсә булганын һәм хакимиятнең аны торгызу өчен нинди чаралар күрергә җыенганын белергә теләдек.

Кызганыч, зират директоры урынында юк иде, әмма ватылган кабер ташының кисәкләрен безгә күрсәттеләр. Зират хезмәткәрләре аны аллеядан алып, зират складына күчергәннәр. Алга таба нәрсә булачак? Без бу хәлне күзәтүне дәвам итәчәкбез.

●**Галим Айдар Гайнетдинов ялган табличка янында.**
Фото: © «Миллиард.Татар».

Ибраһим Юнысов – беренче гильдия Казан сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе, Казанның мактаулы гражданины булган, дип искә төшерде Айдар Гайнетдинов. Абыйсы Исхак белән бергә ул Казандагы сабын, шәм заводлары һәм башка предприятиеләрнең хуҗасы булган. Предприятиеләрнең еллык килеме 1,5 миллион сумга җиткән.

Юнысовлар – Казанда мөселман балалар приютына нигез салучылар. Алар Нурулла мәчетен, мәдрәсәләр төзегәннәр һәм аларны тәэмин итеп торганнар.

Юнысов дин белгече һәм татар тарихчысы Шиһабетдин Мәрҗани белән үзенчәлекле мөнәсәбәтләргә ия булган. «Ибраһим Юнысов Мәрҗани белән таныш була һәм аңа ярдәм итә, ләкин соңыннан алар арасында конфликт килеп чыга. Ул Мәрҗанинең үз патронына буйсынуын теләгән, ә Мәрҗани моның белән ризалашмаган, чөнки ул ирек сөюче һәм горур кеше булган. Әмма ахыр чиктә, Юнысов үлгәч, мәрхүмгә багышланган доганы нәкъ менә Мәрҗани укыган», – дип сөйли Гайнетдинов.

Ибраһим Юнысов фигурасының мөһимлеген аңлар өчен, 1863 елда император Александр II нең өлкән улы бөек кенәз Николай Александровичның Казанга килеп, бай татар йортының нинди булуын күрергә баруын искә төшерү дә җитә. Аңа Юнысов йортын тәкъдим итәләр. Йортка килеп, бай мөселман хатын-кызларын күргәч, кенәз: «Россиядә алтын бетте. Ул хәзер татар хатын-кызларының бизәнү әйберләрендә», – дип әйтә.

Сәүдәгәр тарихка үзенең хәйриячелеге белән генә түгел, ә экстравагант гамәлләре белән дә кереп калган. «Озын Ибрай» бик мәзәкче кеше булган. Бервакыт Ибраһим-бәй шәкертләрне (студентлар, билгеле булганча, һәрвакыт ач) үз өенә чакыра һәм алар алдына махсус рәвештә гади ризык куя. Кунаклар шуларны ашап бетергәннән соң, Юнысов затлы ризыклар бирергә кушкан, әмма кунакларның инде корсаклары тулган булу сәбәпле, аларын ашый алмаган.

«Бу яңалыкны ишетү миңа бик сәер», – дип аңлатма бирде Казанның туган якны өйрәнүче һәм экскурсоводы Марк Шишкин.

(Дәвамы 4 нчы биттә).

Мөнәсәбәт

Моңсуландыра һәм рухландыра торган мизгелләр

Яшәештә шактый каршылыклы һәм гади мантыйкка гына түгел, хәтта могыйшәт кануннарына да буйсынмый торган күренешләр ишәя башлады. Андый тайпылышлар, дөнья тотучыларның нәфес азгынлыгына вә комсызлыгына бәйле рәвештә, Җирдә үткәрелә торган җинаятьчел глобаль сәясәт һәм аны гамәлгә ашыру ниятендә оештырылган һәртөрле провокацияләр ята. Ни аяныч, болар һәммәсе дә көндәлек чынбарлыкка әйләнде. Димәк, Җирдә бүген әхлак нормаларын һәм моңа кадәр гамәлдә булган рухи принципларны җимерү, җәмгыятьне традицион кыйммәтләрдән арындыру, шул рәвешле, дөнья тотучылар ихтыяҗына җавап бирә торган «яңа дөньяви тәртип» урнаштыру өчен җирлек әзерләү бара.

Ә вакыйгалар сөреше глобаль процесслар өчен акыл ышанмаслык темплар алды, дисәк тә арттыру булмастыр. Мондый вакыйгалар өчен кыска вакыт аралыгында: «Глобаль Көнбатыш»ка (нигездә, «Зур җиделек» һәм НАТО) альтернатива буларак, «Глобаль Көньяк» (БРИКС һәм ШОС илләре тирәсендә туплану) формалаштырылды; Якын Көнчыгышта күптәннән пыскып килгән шомлы низаг, ХАМАС хәрәкәтен кулланып оештырылган провокация ярдәмендә, яңа көч белән кабызып җибәрелде; узган атнада Кытайда, колачлы итеп, «Бер пояс – бер юл» дигән халыкара форум үткәрелде, анда КХР рәисе Си Цзиньпин һәм РФ президенты В.Путин өч сәгатьтән артык күзгә-күз карап сөйләшкән; РФ Дәүләт Думасы «Атом-төш сынаулары үткәрүне гомуми тыю турында» (ДВЗЯИ) БМО тарафыннан 1996 елда кабул ителгән килешүне (Россиядә ул 23 ел элек ратификацияләнгән иде) ратификацияләүне кире чакыртып алу турындагы закон проектын бертавыштан кабул итте; АКШ президенты Джо Байден Америка халкына бу вазифада юллаган икенче мөрәҗәгатендә «михнәт чигүче яһүд халкы» турында сөйләгән, асылда, «диктатор Путин»ны «ХАМАС террорчылары» белән бер рәткә куйган, Израильне һәм Украинаны финанслау буенча АКШ конгрессына «ашыгыч бюджет запросы» юллаячагы турында да белдергән. Күрүебезчә, глобаль әһәмияткә ия вакыйгаларның санап үтелгәннәре генә дә күп нәрсә турында сөйли. Ә Израиль һәм Украинаның бер рәткә куелуы инде дөнья тотучыларның якындагы ниятләренә дә күпмедер дәрәҗәдә ачыклык кертә.

Шуның белән бергә, соңгы вакытларда күзәтелә торган атом-төш йөгәнсезлеге һәм БМО кризисы чорында купкан гайре табигый күренешләр инде дөнья тотучы кавем меңъеллыклар дәвамында илаһият кануннарыннан читләшеп корган идарә системасында да геосәяси кризис башлануы турында сөйли. Ә аңа бер генә альтернатива бар: Җирдә яшәешне җайга салуда өстенлекне метасәясәткә (илаһи канунлар буенча яшәүгә күчү сәясәтенә) бирү. Мәгълүм булганча, илаһият кануннары бөтен тереклек дөньясы вә мәгыйшәт өчен (димәк, барлык халыклар вә диннәр өчен дә) уртак. Ә андый кануннар буенча яшәүгә инде бары тик илаһи Ислам дине тирәсендә берләшеп кенә ирешеп була. Бу атнада АКШ президенты Джо Байден, Икенче бөтендөнья сугышыннан соң урнаштырылган дөньяви тәртипнең искерүе, инде Җирдә «яңа дөньяви тәртип» урнаштыру вакыты җитүе, ә аны бары тик АКШ тирәсендә тупланып кына урнаштырып булуы турында да белдерде. Ни гаҗәп, Кремльнең матбугат хезмәте башлыгы Д.Песков аның беренче ике өлеше белән шундук килеште. Ул яңа тәртипне Америка тирәсендә урнаштыру мөмкинлеген генә кире какты, монда аның белән дә килешергә кирәктер. Чөнки, илаһият кануннарына нигезләнгән һәм бөтен кешелек дөньясы вә мәхлукат ихтыяҗларына да җавап бирә торган дөньяви тәртипне илаһи Ислам тирәсендә берләшеп кенә урнаштырып була, дидек. Ә Ислам яңарышы бары тик Урталык җирләреннән (Изге Болгар җиреннән) генә башланып китә ала.

Ләкин, танырга кирәктер, гомуми вәзгыять бүген Россиянең үзендә дә гаять катлаулы һәм моның эчке вә тышкы сәбәпләре бар. Сан ягыннан анда икенче урында торган милләт буларак, татар халкының да бүгенге хәле мактанырлык түгел. Өстәвенә, аңа карата «тырнак астыннан кер эзләү»ләр бүген дә дәвам итә. Бәгъзеләр хәтта Россиядә әзерләнгән яңа 1000 сумлык купюраларга төшерелгән Сөембикә манарасындагы ярымай өчен дә татар халкын гаепләү җаен тапты. Ни кызганыч, үзенә йөкләнгән җаваплылыкны тою һәм тану әле татар зыялыларына да җитми. Асылда, бүген ул үзенең күренекле шәхесләрен соңгы юлга озатканда гына үзара очрашып аралаша ала. Җөмләдән, бу урында татарның мәшһүр улы, соңгы ярты гасырдан артык чорда шигърияттә ат уйнаткан олуг шагыйрь, татар милләте һәм Татарстан тормышында тирән эз калдырган җәмәгать вә дәүләт эшлеклесе, узган җомгада инде бакыйлыкка күчкән милләттәшебез Разил абый Вәлиевнең якты рухы алдында баш иеп, «Мәдәни җомга»ның даими укучылары исеменнән аның туганнары вә якыннарының тирән кайгысын уртаклашам. Күпкырлы бу талант иясе турында киләчәктә әле күп сөйләнер һәм язылыр да. Әмма аны соңгы юлга озату мәрәсимендә алган кичерешләр шәхсән үземне кулга каләм алырга мәҗбүр итте. Ә инде татар милләтенә килгәндә, Җанабе Хак бүген аңа Урталык җирләрендә тотрыклылык һәм Ислам яңарышы факторы булу бурычын йөкли. Илаһи миссияле милләт буларак, мондый форсатны кулдан ычкындырырга аның хакы юк. Ә бу инде милләттәшләребездән, аның кайда яшәвенә һәм нинди вазифада булуына карамастан, зур җаваплылык вә фидакарьлек таләп итә.

Фоат УРАЗАЙ.

Атласи мәктәбендә очрашу

Якты уйлар, күңелне җылытырлык сүзләр җанга рәхәтлек бирә. Шушындый катлаулы тормыш юлында үз кыйблаңнан тайпылмыйча, көр күңеллелекне, ихласлылык, эчкерсезлекне саклап, пакь күңелле булып, ничек итеп үрләргә юл табарга? Казаннан безнең шәһәребез татарлары белән очрашуга килгән мәртәбәле кунакларыбызда бу сыйфатларның барысы да бар. Моңа без алар белән бик якыннан күзгә-күз карашып, аралашканнан соң инандык.

Аларның берсе – татар шагыйре, филология фәннәре кандидаты, Татарстан һәм Россия Язучылар берлекләре әгъзасы, Татарстанның Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Гамил Афзал исемнәрендәге исемендәге әдәби премияләре лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире Ленар Шәехов, икенчесе – аның тормыш иптәше – язучы, драматург, журналист Айсылу Имамиева. Аларның кыскача тормыш һәм иҗат юлы белән танышканнан соң, кунакларыбыз үзләренең иҗат җимешләре белән таныштырды: шигырьләрен, хикәяләрен укыды. Аннары 14 нче гимназия укучылары кунакларның шигырьләрен яңгыратты, зал белән авторлар арасында кызыклы әңгәмә үткәрелде.

Очрашуга Баулы шәһәреннән татар халык театры җитәкчесе, режиссер Сәгыйть Әхмәтҗанов үзенең иҗатташ дуслары белән килгән иде. Алар үзләренең моңлы җырлары белән кичәбезгә ямь өстәде.

Л.МӨҺИМОВ,
Бөгелмә.

Әфганстан татарларын Татарстанга күчермәкчеләр

Гератта җир тетрәү нәтиҗәсендә торыр җирләрен югалткан Әфганстан татарларын Татарстанның ташландык авылларына күчерергә мөмкиннәр. Россиянең Әфганстандагы элекле үзәге җитәкчесе, Россия мөселманнарының Казан хәйрия патриотик фонды генераль директоры Рөстәм Хәбибуллин шундый фикер белдерде.

«Герат провинциясендә җир тетрәүләрдән ким дигәндә 200 татар һәлак булды. Әлегә кадәр зыян күрүчеләрнең исәбе алып барыла. Кышка кергәндә 40 торак пунктта яшәүчеләрнең күбесе йортсыз калган, алар арасында безнең күп санлы кардәшләребез, татарлар бар. Өстәвенә, авыл хуҗалыгы һәм терлекчелек белән шөгыльләнгән авыл районнары халкы зыян күргән. Һәм мин Татарстан Республикасы җитәкчелегенә Әфганстан татарлары гаиләләрен Татарстан районнарының ташландык авылларына күчерүне карарга тәкъдим итәм. Уңай яклары күп. Әфганстан татарлары бу җирләргә кабат тормыш бирәчәк. Алар сарык үстерүдә тәҗрибәле, һәм алар бездә хәзер югары дәрәҗәдә булмаган терлекчелекне торгызырга булышачак. Фермаларны ремонтларлар һәм буш кырларны чәчәрләр», – дип саный Рөстәм Хәбибуллин.

Ул Кыргызстанда күптән түгел генә шундый программа уздыруын да әйтте. Әфганстанның меңләгән кыргызлары Кыргызстанның авыл районнарына күченгән, һәм нәтиҗә уңай булган.

«Минемчә, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Әфган татарларының газап-кайгысына игътибар итәр һәм Татарстанда шундый ук программаны яклар. Шуның белән Әфганстан татарларына да ярдәм күрсәтеләчәк һәм Татарстанда ташландык авылларны торгызуга да адым ясалачак», – ди Рөстәм Хәбибуллин.

tatar-inform.tatar.

«Роскосмос»тан 600 миллион сум акча урлаучы качкан

«Роскосмос»ның элеккеге топ-менеджеры һәм РФ Президентының Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле аппаратында департамент җитәкчесе урынбасары Владимир Мешков Россиядән качып киткән. Бу хакта Газета.Ру сайты яза.

Басма мәгълүматлары буенча, Мешковны халыкара эзләүгә биргәннәр. Тикшерү комитеты мәгълүматларына караганда, дәүләт корпорациясенең элекке топ-менеджерын 600 миллионнан күбрәк акча урлауда гаеплиләр. Бу акча Ракета-космос сәнәгатенең Фәнни-сынау үзәгенең стенд базасын реконструкцияләү өчен бирелгән була.

Эзләүдә булган Мешков 2 айга кулга алынган. Бу срок аны чит илдән экстрадицияләгәч һәм Россия территориясендә кулга алгач исәпләнә башлый.

1 нче биттә – Зифа Басыйровага багышланган фотоколлаж.

Алтын Урдада «башкорт ханнары» булмаган

Тарихчылар фикеренчә, Идел буе һәм Урал төбәкләрендә ачыкланган барлык төрбәләр XIII-XV гасырларда Алтын Урданың төрле төбәкләрендә булган күп санлы төрбәләргә охшаш. Казан һәм Уфа галимнәре Алтын Урдадан калган төрбәләрнең «башкорт ханнары»на катнашы булмавын белдерә.

12 октябрьдә Чиләбе өлкәсе Варна авылында «Идел-Урал, Кырым һәм Казахстанның урта гасыр төрбәләре: тикшеренү проблемалары» дип аталган түгәрәк өстәл утырышы узган. Чарада Казаннан Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре, Башкорт педагогия университетының баш фәнни хезмәткәре Владимир Иванов, Россия Фәннәр академиясенең Уфа федераль тикшеренү үзәгенең күче фәнни хезмәткәре Алексей Нечвало да катнашкан.

Мәгълүмат өчен: Башкортстанда кайбер төрбәләрне мөтәгалимнәр, алар, имеш, «башкорт ханнары»ныкы булган, дип яза.

«Идел буе һәм Урал төбәкләрендә ачыкланган барлык төрбәләр XIII-XV гасырларда Алтын Урданың төрле төбәкләрендә булган күп санлы төрбәләргә охшаш. Аларның Алтын Урда мәдәниятенә хас бердәм стандарт буенча төзелүенә шик юк. Бу һәйкәлләр барысы да утрак мөселман цивилизациясенең бер өлеше булып тора. Төрбәләрне ниндидер билгесез «башкорт ханнары» белән бәйләргә һәм аларны XVI гасырга кертергә нигез юк», – диелә түгәрәк өстәл утырышы резолюциясендә.

Р.КАЮМОВ.

Халыкның асыл шагыйре

20 октябрь иртәсендә күренекле җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиевнең йөрәге тибүдән туктады. Шагыйрьгә 77 нче яшь иде.

Разил Исмәгыйль улы Вәлиев 1947 елның 4 гыйнварында Түбән Кама районының Ташлык авылында туа. 1973 елда Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый. 1972 елдан 1981 елга кадәр «Ялкын» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркатиб булып эшли.

1981-1984 елларда – Чаллы язучылар оешмасының җаваплы секретаре. 1984-1985 елларда – ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары.

1986-2000 елларда – Татарстан Милли китапханәсе директоры. 1990 елдан Татарстан халык депутаты итеп сайланды. 2019 елга кадәр Татарстан Дәүләт Советы депутаты булды. II чакырылыш Дәүләт Советында Фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссияне җитәкләде, III һәм V чакырылыш Дәүләт Советында шул ук комитет белән җитәкчелек итте.

Россия һәм Татарстан Язучылар берлеге, Россия һәм Татарстан Әдәбият фондлары әгъзасы. 2000 елдан – Татарстан Милли китапханәсенең Попечительләр советы рәисе. Бөтендөнья Язучылар оешмасының Татар Пен-үзәге вице-президенты. Түбән Кама районының почетлы гражданы.

Татарстан Республикасының халык шагыйре. Россия һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. М.Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты, А.Алиш исемендәге әдәби премия, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Татарстан «Фидакарь хезмәт өчен» (2016) медале, Россия һәм Татарстанның башка медальләре белән бүләкләнгән.

Р.Вәлив белән хушлашу мәрасиме мәркәзнең Г.Камал исемендәге академия театры залында үткәрелде, Мәрҗани мәчетендә аңа җеназа укылды. Мәрхүм Казан читендәге Курган зиратында җирләнде.

Фәләстыйн – уртак фаҗига

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Фәләстыйнда барган фаҗигале вакыйгалар, дин кардәшләребезнең Израил тарафыннан геноцидка дучар ителүенә мөнәсәбәтле мөрәҗәгать белән чыкты. Анда болай диелә: «Көн саен безгә Фәләстыйндәге дин кардәшләребезнең үлемнәре турында берсеннән-берсе аяныч хәбәрләр ирешә. Авырулар, балалар, хатын-кызлар, картлар, тыныч халык сыену урыны тапкан хастаханәне утка тоту – чираттагы, әмма барлык чикләрне узып киткән, Фәләстыйн халкын юкка чыгаруга юнәлтелгән коточкыч хәл. Ул халыкара ислам җәмәгатьчелегенең Фәләстыйнны җир йөзеннән юкка чыгару турындагы кисәтүләрен раслады.

Тыныч халыкны юк итүнең ерткыч, вәхши ысуллары Гитлер нацистларының җинаятьләрен искә төшерә.

Хөрмәтле дин кардәшләр! Фәләстыйн халкын камалышта тоту аңа гуманитар ярдәм күрсәтүне катлауландыра. ТР мөселманнары Диния нәзарәте хәзерге вакытта Газәдәге мөселманнарга ярдәм җибәрү мөмкинлекләрен өйрәнә һәм акча җыю турында өстәмә рәвештә хәбәр итәчәк. Хәзер исә без догада булырга тиеш. Мин Татарстан имамнарын бу көннәрдә һәр намаздан соң Фәләстыйн өчен дога кылырга һәм аны азат итү һәм коткару өчен Коръәнне хәтем чыгарга чакырам. Аллаһ болай ди:

«Раббыгыз әйтте: «Миңа дога кылыгыз, сезгә җавап бирим. Һичшиксез, Миңа коллык итүдән тәкәбберләнгән кешеләр җәһәннәмгә китәчәк» («Гафир», 60 нчы аять).

Бүгенге көндә Фәләстыйн бөтен халыкара тәртипләрне бозган рәхимсез көч куллануга, террорга һәм камалышка дучар ителә. Мин үзем һәм Татарстанның барлык имамнары исеменнән илебез җитәкчелегенә бу авыр көннәрдә кардәшләребезгә ярдәм итү теләге өчен рәхмәт белдерәм. Без Фәләстыйн халкы өчен кайгырабыз һәм аларның фаҗигасен уртаклашабыз. Ислам өммәте һәм халыкара җәмәгатьчелек, булган хәлләрне хөкем итеп кенә калырга түгел, ә Фәләстыйн халкын Израиль агрессиясеннән һәм оккупациясеннән яклау чараларын да күрергә тиеш.

Йа Рабби! Мөселманнарны явызлыктан һәм җәберләүдән сакла, аларга дошманны җиңәргә мөмкинлек бир һәм Фәләстыйндагы башбаштаклыкны туктат».

Башкалабыз мәчетләрендә Фәләстыйн халкы өчен җәмәгать белән дога кылу да оештырылды.

Э.СИРАҖИ.

Ибраһим Юнысов һәйкәлен кем җимергән?

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Аның сүзләренчә, кыйммәтен әле исбатларга кирәк булган йортлар, архитектура элементлары һәм һәйкәлләр югала.

«Ләкин бу очрак бернинди кысаларга да сыймый. Казанда Юнысовлар династиясе истәлегенә бәйле барлык объектларның кыйммәтен беркемгә дә исбатларга кирәкми. Нәкъ менә хәзер Юнысов мәйданы төзекләндерү тәмамланып килә. Казанда хәйрия эшләренә багышланган бер генә чара да 1844 елда ук нигез салынган Юнысов мөселман приютын искә алмыйча үтми. Бу ничек булырга мөмкин?» – ди эксперт.

Кабер ташының җимерелүе белән бәйле хәлгә без Мәрҗани мәчете имам-хатыйбы Мансур Җәләлетдиновтан аңлатма бирүне сорадык.

«Мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани: «Мин үлгәч, 4 кеше күтәрә алмаслык кабер ташы куегыз», – дигән. Кабер ташларын юк итү – дөрес түгел һәм теләсә кайсы дин өчен вандализм акты булып тора. Мин болай дип әйтер идем: бүгенге көндә яшьләр үз халкының һәм аның танылган шәхесләренең тарихын белми. Әгәр вандаллар бу һәйкәлнең кемнеке икәнен белсәләр, алар аңа кагылмаслар иде. Бүгенге көндә яшьләрне тәрбияләүгә тиешле игътибар бирелми. Яшьләр зират территориясенә кереп, анда хәтта эчеп утырырга мөмкин, чөнки анда аларны полиция һәм кешеләр күрми», – ди имам-хатыйб.

● Юнысовлар гаиләсе. XX гасыр башы фотосы.

● Юнысов-Апанаевлар йорты. Реставрациягә кадәр. Фото: © history-kazan.ru

Мансур хәзрәт фикеренчә, кабер ташы табигый сәбәпләр аркасында да җимерелергә мөмкин. «Табигать тәэсире аркасында кабер ташлары җимерелгән очраклар күп булды», – дип билгеләп үтте ул.

• Ибраһим Юнысов (1806-1886) танылган татар сәүдәгәрләре Юнысовлар нәселеннән булган.

• Замандашлары аны сәүдәгәр, хәйрияче, меценат дип атый. Ул – мөселман балалар приютын оештыручы.

• Хәйриячелек өчен III дәрәҗә Изге Анна ордены һәм медале белән бүләкләнгән.

«Миллиард.Татар» сайтыннан тәрҗемә ителде.

● Товарларны өйгә китереп бирү хезмәтендә эшләүче дипломлы белгечләрнең өчтән бере – инженер-техник белемле, 17 проценты икътисад яки финанс факультетын тәмамлаган, 10 проценты – компьютерчы. Россия курьерларының 40 проценты югары һәм тәмамланмаган югары белемле, диелә быел августта үзенең 5700 хезмәткәре арасында үткәрелгән «Яндекс.Доставка» тикшеренүендә. Ә hh.ru порталы мәгълүматлары буенча, курьерларның 27 проценты югары һәм тәмамланмаган югары белемле икән.

● Узган ел белән чагыштырганда, курьерларның кереме якынча 30 процентка арткан: былтыр көз аларның эш хакы аена 30-60 мең сум тирәсе булса, быел 45-95 мең сумга җиткән. Зур шәһәрләрдә үзмәшгуль буларак теркәлгән курьер кайбер компанияләрдә аена 100 мең сумнан артыграк акча эшләргә мөмкин.

Бергәләп фикерләшергә чакыру

Әле күптән түгел генә Татарстан китап нәшриятында Зиннур Мансуровның «Мең дә бер уй» дигән җыентыгы дөнья күрде. Шагыйрьнең ошбу үзенчәлекле мәҗмугасында мәгънәви әйтелмәләр туплап бирелгән. Хәтерлисездер, төрле темаларны яктырткан әлеге гыйбарәләр «Мәдәни җомга» газетасында дөнья күреп барды. Алар белән, ниһаять, тулаем танышырга мөмкин. Татар һәм рус телләрендә шундый китап басылу уңаеннан авторның үз укучыларына махсус рәвештә язылган мәкаләсен тәкъдим итәбез.

Аксиомадай аңлашылганча, адәм баласын гасырлар дәвамында тәрбияләп килгән әдәбиятны бәрәкәтле уй-фикер башлангычыннан аерып күзаллау мөмкин түгел. Әгәр сүз мантыйкый төшенчәне белдергән иң кечкенә лексик берәмлек булып санала икән, сүз белән эш итүче каләм иясенең «акыл казаны» һәрдаим кайнап торырга тиеш. Әлеге мөһим зарурият хакында атаклы классиклар да искәрткән. Әйе, тирән рәвештә зиһенли белмәүче әдип олуг бурычларны башкарып чыга алмый.

Билгеле чынлыкны кабатлап әйткәндә, Аллаһ кешегә уйлый белү, фикер йөртү сәләтен биргән. Иҗтимагый яшәеш барышын сәнгатьчә югарылыкта сурәтләү өчен, әлбәттә, ошбу сәмави нигъмәтнең иҗатчыда тулысынча ачылуы сорала. Тынгысыз рух дулкынында туктаусыз бәргәләнгән затның дөнья гаменнән арына алмавы бик табигый. Акыл көче, мәгънәви йөкләнеш, зирәклек тирәнлеге... Болар әсәрнең тәэсирлелеген бермә-бер арттыруга, ахыр чиктә язылганның әһәмиятен билгеләүгә хезмәт итә. Менә шундый очракта гына образлы җирлектәге зур гомумиләштерүләргә ирешеп, әдәби китапны буыннарга тәгълим кылырлык тормыш дәреслегенә әверелдереп була.

Гамәлдә расланып торганча, образлы фикерләү тәҗрибәсе иҗади хезмәтнең мәгънәви сыйдырышлылыгын киңәйтүгә китерә, камиллеккә омтылучы каләм остасын үзеннән-үзе лаконик сурәтләү биеклегенә күтәрә. Гадәттә, укучы күңелендә көтелмәгән ассоциацияләр уяткан фразалар аерым әсәр кысаларында гына калмый, алар коммуникатив яссылыктагы тотрыклы тел берәмлеге рәвешендә отыры зур дөньяга тарала. Канатлы сүзләр хәзинәсен тикшереп чыксак, анда моның ише үрнәкләр бихисап. Мәшһүр галимнәр, философлар, дәүләт эшлеклеләре дә бу җыелмага үзләренчә саллы өлешләрен керткән. Һәм башкалар да...

Чагыштырып караганда, күптөрле чыганаклардан алынган гыйбарәләр арасында, әлбәттә, шагыйрьләр каләменнән төшкәннәре ишлерәк күренә. Гомумән, бездә хикмәтле сүз әйтергә омтылу, традиция буларак, әдәбият тарихының борынгы чорларыннан килә. Әлбәттә, халкыбыз афоризмнары тупламында төп урынны биләгән мәкальләр язусыз яшәлгән әүвәлге ыруглык җәмгыятендә үк күзәтелгән. Фонетик чаралар ярдәмендә камиллек дәрәҗәсенә күтәрелгән әлеге тел берәмлекләре импровизация ясарга сәләтле чичәннәр катнашыннан башка гына әйләнешкә кермәгән. XII гасыр төрки-татар шигъриятендә исә хикмәт башлангычы аеруча көчәеп китә. Аның чишмәсен Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакыргани кебек мәгълүм затлар киңәйтеп җибәрә, аннары Сәйф Сараи, Мәүлә Колый һ.б. бу тенденциягә бәрәкәтле куәт өсти.

Әдәби әсәр тукымасында җемелдәп торган фикер җәүһәрләренең еш кына мөстәкыйльлек алуы бөек шагыйребез Габдулла Тукай иҗаты мисалында бигрәк тә дәлилле рәвештә чагыла. Сокландыргыч халыкләшу бәйләнеше! Аның язганнарында аерым игътибарга лаек 150 ләп тәгъбир безнең кавемне зурлап күрсәткән мәкальләр хәзинәсенә күчкән. Шәхсән үземә Тукайның бинийая зур мирасыннан канатлы сүзләрне берәмтекләп тупларга туры килде. Алар байтак җыелды – җәмгысы 400 дән артык. Катлаулы чынбарлыкның сөземтәсенә охшаш әлеге гыйбарәләр иҗтимагый яшәешнең һәрбер тәкъдири очрагына ярашлы. Ирексез гаҗәпләнеп куясың. Әйе, могтәбәр Мифтахетдин Акмулла тикмәгә генә әйтмәгән: «Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән...»



Хикмәтле сүзне үтә җентекләп эшкәртелгән кыйссага тиңлиләр икән, мәкальләрне күздә тотып әйткәндә, безнең халык бихисап кыйсса иҗат итүче булып чыгадыр.

Мәгълүм ки, махсус рәвештә афоризм язу, әдәби жанр буларак, XVII гасырда тамыр җәя. Хикмәтле гыйбарәнең асыл хасияте тагын да тулырак ачыклана, эчтәлеге җәһәтеннән ул табигый шәкелдә калыплашу камиллегенә ирешә. Аның көтелмәгән парадоксаль мәгънәсе алгарак чыга, шигъри образлылыгының тәэсирлелеге бермә-бер арта. Шулай капма-каршы төшенчәләрне синтаксик янәшәлеккә кую, әлбәттә, тормыш коллизияләрен тирәнрәк ачарга ярдәм итә. Яшәеш тәҗрибәсен гыйбрәтле нәтиҗә рәвешендә гомумиләштергән чакта, хәтта иҗтимагый антагонизм чагылышына да урын табыла. Афоризм өслүб ягыннан да зур үзгәрешләр кичерергә өлгерә. Әйе, акыл уенчаклыгы гадәти сүзләрне ирониягә дә, усал сарказмга да борып җибәрергә мөмкин. Алар безне уйландыра да, кайчак елмайтып та ала. Кыскасы, уены-чыны бергә.

Дөресен әйткәндә, татар әдәбиятында афоризм жанрын үзләштерү нәтиҗәлелек ягыннан алай мактанырлык түгел. Чынлап та, уй-фикерне кәгазьгә төшерүнең әлеге төренә мөрәҗәгать итү үткән гасырлар дәвамында әлләни күпләп күзәтелми. Эш арасында гына язылган канатлы җөмләләр очраштырып куя. Тик алар аз. Ярый әле, мәгърифәтче галим, тарихчы, язучы, дин белгече, җәмәгать эшлеклесе Ризаэддин Фәхреддин «Гыйбрәтле сүзләр» дигән гомуми исем астында шундый тәгъбирләрен теркәп калдырган. Мәгънәви кыскалык үрнәкләре сирәк-мирәк күренеп киткәли. Мәсәлән, халык язмыш җәүһәрләренә мөнәсәбәтен һәрдаим белдерен яшәгән әдибебез Гомәр Бәшировның «Яхшы фикерләр, акыллы сүзләр», шагыйрь Шәүкәт Галиевнең «Хикмәтле сүзләр» шәлкемнәре талымлы укучылар күңелендә ничектер тансык ризыктай һәйбәт тәэсирләр уятты. Ошбу юнәлештә үзләрен сынап караучы каләм әһелләре, шөкер, бүгенге интеллектуаль үсеш чорында беркадәр арта төште.

Инде байтак еллар әдәби иҗат белән мәшгуль булганлыктан, төрле-төрле фикерләр шәхсән үземнең башымнан да китеп тормый. Кайсыбер вакытта бәйләнчек уй сиңа төштә дә тынгылык бирергә теләми. Алар әледән-әле бөтен вөҗүдеңне үрмә гөлдәй урап ала, мондый халәттә аяк-кулың да кешәнләнгән кебек тоела башлый. Каяндыр чәнечкеләре дә калкынып, бәгырьдә авырту барлыкка китерә. Шулчак ирексездән бушанасы килә. Ашыгып каләмгә үреләм. Мөһимрәк саналган уй-фикерләр көндәлек битенә яки аерым кәгазь кисәгенә төртеп куела. «Төртке»ләрнең беришесе йә шигырь, йә мәкалә язганда файдаланыла. Мөстәкыйль мәгънәле әйтелмә рәвешендә теркәлеп, үзбашка яшәрдәйләре дә күпләп җыела.

Хөрмәтле укучым, зиһен ятьмәсендә тупланып килгән менә шундый мәгънәви берәмлекләрне тәртипләп, аларны китап рәвешендә синең хөкемеңә тәкъдим кылырга җөрьәт иттем. Әлбәттә, үземне югарыда искә алып үтелгән мөхтәрәм шәхесләр янәшәсенә куярга, олыдан купкандый, әлеге җөмләләремне халык телендә йөргән афоризмнар төркеменә кертергә теләмим. Канатлымы ошбу сүзләрем – анысы киләчәктә ачыкланыр. Һәрхәлдә, мондый җыелма кемдәдер зуррак фикерләр тууга этәрер, бергәләп уйлашу өчен ниндидер җирлек бирер төсле. Шуңа ихластан ышанам.

Зиннур МАНСУРОВ,
Татарстанның халык шагыйре.

Ике «бишлелек» шагыйрь

«Ул – милли шагыйрь. Татарның күңелен аңлап, аның хыялый максатларын да, үткәндәге драмаларын да җаны-тәне белән тоеп яза. Ул, зур эпопеялар белән мавыкмый, гади кешеләрнең гади хис-кичерешләрен, көндәлек тормыш-яшәеш вакыйгаларын сурәтли, милләтебезнең чын, асыл сыйфатларын барлый, әхлакый һәм иманый тәгълиматын яза», – ди бу сыйфатлар турында Р.Шаһиевның «Сагыну хисе» китабының беренче битләрендә аның авторы, әдәбият белгече Галимҗан Гыйльманов.

Бу абзац Рәфкать Шириаздан улының киңкырлы иҗатын тәгәл тасвирлый. Үзен әдәбиятка 40 яшьтән соң гына килдем дип санаса да, кыска вакыт эчендә ул үзенең укучысын тапкан үзәнчәлекле прозаик. Берничә китап, дистәләгән шигырьләр, йөзләгән язмалар авторы, әдәбиятта үз сукмагын тапкан һәм абруен булдырган шәхес ул.

Беренче һөнәре буенча Лениногорск педагогия училищесында рәсем сәнгате бүлегендә белем алгангамы, әллә әти-әнисе биргән тәрбиядәнме, Р.Шаһиев тирә-юньдәге матурлыкны тоемлый, күрә белә. Күңелендәге яктылыкны ул укучыларына үзенең иҗаты аша җиткерә.

– Мин үзем әдәбиятка чагыштырмача соң килдем. Язучылар берлегенә кергәндә 40 тан узган идем. Аңа кадәр дә язмыйча тормадым, ләкин актив рәвештә иҗат итү хасияте соңыннанрак туды. Иҗатта күп нәрсәгә тәнкыйть белән карыйм. Өлкәннәр лаеклы ялга чыккач, вакытлары күбәйгәч, яшьлек елларындагы мәхәббәтне сагынып, шигырьләр иҗат итә башлый. Алар үткәннәрне сагынып яза. Килешәм, мәхәббәтсез яшәп булмый. Унсигездә ул башка, 25 тә – бүтән, 40-50 тә – гел үзгә. Тик иҗат кешесе яшен онытып җибәрүчән. Миңа калса, мәхәббәт турында 60 яшьтә язганда синдә 60 еллык тормыш тәҗрибәсе, дөньяга башка караш формалаша. Синең фәлсәфәң башка төрлерәк булырга тиеш. Кайчан киләсең, нигә килмәдең, мин көттем сине, дип кенә түгел. Мәхәббәт – ул аерылу турында гына түгел бит. Кеше үткәннәр белән яши, шуңа күрә иҗатта артка карау күзәтелә, ә монда алга карарга кирәк. Кайчандыр булган мәхәббәтне сагынып яту – инде дөрес түгелдер. Син менә көн дә күреп торган иреңне, хатыныңны ярату турында яз. Миңа калса, шулай булырга тиеш. Бәлки, син яшьлек мәхәббәтеңне һаман да яратасыңдыр, чөнки ул синең белән яшәми, син аның начар ягын күрмисең. Тик шуны онытмаска кирәк: гомер буе синең янәшәңдә, синең белән тормышның бөтен авырлыгын, шатлыгын татыган кеше назлы сүзгә күбрәк лаек, – дип билгели Рәфкать әфәнде.

Үзенең шигырьләрендә Р.Шаһиев төрле темаларны күтәрә, халыкка әйтәсе фикерен шигъри юллар аша белдерә.

– Бу – минем гражданлык позициям. Бәлки, кемгәдер, нәрсәдер исбатларга тырышу да бардыр иҗатымда, ләкин мин чебен дулап тәрәзә вата алмаганын яхшы аңлыйм. Тик икенче ягы да бар. Дини риваятьтә янгын вакытында бер чыпчык, томшыгына алып, ут сүндерергә су ташый. Аннан шулай итеп янгынны сүндерәсеңме, дип көләләр. «Юк, сүндерә алмыйм, тик Кыямәт көнендә Аллаһ каршысында син менә шуны булдырмас өчен ни эшләдең? – дип сорасалар, минем дәлилем бар, – ди ул. Шуның кебек, әлбәттә, дөнья бүгенге белән генә бармый, киләчәктә бүгенге вәзгыять ничек бәяләнер? – менә шул да көтә. Минем шигъри юлларда күбрәк бүгенге дөньяга карашым, бәям, үз фикеремдер. Аны кемдер ишетергә, кемдер ишетмәскә мөмкин. Бүген ишетмәсә, иртәгә, берсе ишетмәсә, икенчесе ишетер. Бу – минем шушы тормышка мөнәсәбәтемне күрсәтү. Мөгаен, шигърияттә нindидер серлелек булырга тиештер инде ул. Миндә әле ул турырак бара. Нәрсәдер артына яшереп бетерә алмыйм, ләкин яшерелгәнен дә кеше аңлый, – дип уртаклаша автор.

2014 елдан бирле Р.Шаһиев ТР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеген җитәкли, өч елга якын – «Әлмәт таңнары» газетасының баш мөхәррире. Җитәкчесе нинди – эчтәлеге шундый. Газета битләрендә ул тормыш-яшәешкә игътибар бирә, халыкның моң-зарын ишетә, гади кешеләрне үрнәк итеп күрсәтә белә.

– Бөтен әйбер кешенең холкыннан, аның эшеннән тора бит. Һәрвакыт читтән карый белергә өйрәник. Кешене нинди сораулар борчый, ни кызыксындыра, бүген аңа нәрсә кирәк? Әйберне читтән күзәткән позиция белән эш итәм мин. Хәтта студентлар белән эшләгәндә, аларга сорау биргәндә дә мин ул әйберне үзем башкача бәяләргә мөмкин, тик шул ук вакытта гади кеше ничек бәяли, шул позициядән карарга тырышам. Коры фактлардан, саннардан тиз туялар. Газета укучы – ул гади халык. Аңа үзенең янәшәсендәге кешеләр турында булган мәгълүмәт кызыграк. Язмаларымны шул күзлектән бирергә тырышам. Әлбәттә инде, кайвакыт түрдәге түрәләрне «тешли» торган язмалар да була. Шуңа да редакциягә хатлар да килә, шундый темаларны күтәреп чыгыгыз дип сорыйлар, – дип сөйли Р.Шаһиев.

Һәр иҗат кешесенең кебек үк, Рәфкать Шириаздан улы иҗатының да гөрләп чәчәк аткан бер чагы була. Бу – Р.Шаһиевның хәзерге вакыты дисәм, ялгыш булмас. Бүгенге көндә социаль челтәрләрдә ул иҗат иткән шигырьләр тиз арада шактый күп комментарияләр җыя, китапханәләрдә узган автор белән очрашу кичәләренә килгән халык саны арткannан-арта бара. Узып баручы елның тагын бер матур яңалыгы – Татарстанның атказанган артисты Марат Галимов белән көтмәгәндә барлыкка килгән уртак җырлары.

– Җыр сүзләренә тәнкыйтъ белән карый идем. Үзем дә шигырь язганда беркайчан җыр өчен текст язам, дип уйламадым. Беренче җыр тексты хатынымның авылы турында язылды. Бүген анда 3 кеше яши. Авыл бетә. Тәтеш районында Берлек дигән авыл ул. Анда ел саен авыл халкы кайта. Берсендә миңа авыл бетә бит инде, һичьюгы җыр булса да теркәлеп калсын, диделәр. Мин махсус җыр өчен текст яздым. Көен Людмила Аланлы иҗат итте. Аннан соң бу эш тукталды, яңадан җыр тексты дигән максат куймадым. Бөтен матур шигырь дә җыр булып яңгырый алмый бит. Узган ел сентябрь ахырында мобилизация башланганда, менә шушы бүгенге кебек бик матур көзге көн иде. Кызыл, сары, чуар. Тик нидер башка. Бөтен авырлыкка адәм баласы өйрәнә, ләкин узган ел мобилизация башлангач, көз матурлыгын югалтты. Яшәеш башка мәгънә алды. «Язлар сары түгел» дигән шигырь илдә мобилизация башланган көннәрдә, 27 октябрьдә язылган иде. Улчак шагыйрә Шәмсия ханым Җиһангирова берничә шигыремне, минем рөхсәт белән, «Мөслим» төркеменә куйды. Мин гадәттә шактый соң ятам. 7 ноябрь иртәрәк ятканмын, ахры. Иртән торуга ватсапка ябышабыз бит. Карыйм, төнге 12 туларга 5 минутта Шәмсия апа язган. «Их син, йокы бәлеше! Телефонны алмадың. Мөслим группасына куйган шигыреңә җыр туды бит! Сөенче алыйм дигән идем... Җырны тыңлагач, минем йокым качты. Каз тәннәре чыкты. Ә син берни белми йоклап ятасың!»

Марат белән иҗади элемтә шулай башланды. Ул җырның аягы җиңел булды. Бу композиция «Яңа татар җыры» бәйгесендә «Ил чакырган чакта» дигән яңа номинациядә беренче урын алды. Марат тагын берничә шигырьгә тиз арада көй иҗат итте. Заманча язылган «Юри йөрмә» җырын Данир Сабиров башкара, Зинира һәм Ризат Рамазановлар бер җырны алды», – дип сөйли Рәфкать Шириаздан улы.

«Илһам миңа эш өелеп торган чакта килә», – ди Р.Шаһиев. 4 юл язып куйганнан соң берничә куплет үзеннән-үзе барлыкка килә икән. Бу инде – табигатьтән бирелгән сәләт. Әлмәт бүлеге җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты буларак, аны әдәбият өлкәсенә килгән яшьләр киләчәге борчый.

«Элек бит коймак калынлыгы китап чыгарып, гонорар алып яшәгәннәр. Бүген дә шулай булсын иде. Нинди талантлы яшьләр бар, югыйсә. Әмма әз генә ялтырыйлар да, әдәбият мәйданыннан югалалар. Бүгенге көндә рухи байлык читкә тибелде. Дөнья матди байлыкка табына башлады. Шул чиргә башка күзлектән карау кирәк. Кешегә ихласлык җитми. Асылда, яшәешне ихласлык саклап кала, – дип саный ул.

Татар әдәбияты тарихында үзенең лаеклы урынын булдырган Әлмәт язучылар бүлеге быел үзенең 60 еллык юбилеен билгеләп үтә. Аның җитәкчесе дә октябрь аенда 55 яшен каршылый. Бу саннар могҗизасы очраклы түгелдер, чөнки үз халкы, татар сәнгате хакына башкарган хезмәте өчен Рәфкать Шаһиев чыннан да ике бишлегә лаек!

Рәмилә ХӘМИДУЛЛИНА.

Марат КӘБИРОВ

Үзәкләрне өзәр көзем бар да, Шул көзләргә түзәр түзем бар...

* * *

Кыр казларымы сез, торналармы?
Ә бу – минем туган авылым.
Мин бу җирдә тудым. Ә сез – күктә,
Тик барыбер миңа, барыбер.

Сез китәсез. Ә мин калам монда.
Калгач инде – көткән булырмын.
Сез кайтырсыз. Бәлки, кайталмассыз...
Бәлки, мин дә киткән булырмын.

Сез дә кайтып, мин дә китми калсам...
Нидер бәйрәм иткән булырбыз...
Йөзәр дусны алган дөньялардан
Тагын нидер көткән булырбыз.

Язлар булган саен, көзләр булыр,
Күзләр булыр сезне күрерлек...
Һәм күңелләр булыр сезнең моңны
Кесәсендә саклап йөрерлек.

Без булырбыз... Бәлки, без дә түгел,
Безнең өчен булыр бүтәннәр...
Күктән яуган үз язлары сыман
Сез кайтуны өзелеп көткәннәр.

Тик барыбер көзен сез китәрсез...
Күккә карар күзләр табылыр...
Кыр казлары ни, сез торналар ни –
Китеп барасыз бит барыбер.

АТНАБАЙГА

Гомерләрнең күпме торганлыгы
Еллар үткәч күбрәк беленә.
Минем гомер синле гомергә һәм
Синсез калган чакка бүленә.

Мине кеше иткән кешем бит син...
Мин әтиле илне белмимен.
Рухым яралганда, абыем да,
Әтием дә булдың син минем...

Һәм мин синең үз теләгең белән
Кече улың иткән баламын.
«Сыңар медаль дә юк, чуртым», – дип,
Синең эздән китеп барамын.

Безне җирдә тоеп кына була,
Булмый тыеп, булмый йөгәнләп...
Башкорт илләрендә – бер Атнабай,
Дәүләт эчләрендә бер дәүләт.

Ә син мине нык яратыр идең,
Сөенер идең... бу дип, чын улым...
Иң яраткан шагыйрем син минем
Һәм мин синең иң шәп шигырең...

Әйбәт шигырь сыман яшәп ятам,
Синең кебек мин дә җиллемен.
Минсез дөньяларда синлемен дә,
Синсез дөньяларда минлемен...

Без бар әле. Бездән соң да калыр
Басучылар хаклык эзенә...
Гомерләрнең күпме торганлыгы
Еллар үткәч күбрәк беленә.

Көннәр үткән саен, мәңгелеккә
Якыная бара арабыз...
Мәңгелектән китеп барган сыман,
Мәңгелеккә китеп барабыз.

СӨН

Роберт Миңнуллинга

Сөннәрдә сине сагынам,
Синдә сагынам Сөнне.
Минем өчен кемлегеңне
Син үзең беләсеңме?

Сөн буйларында моңаям,
Кибә дә кибә бит ул...
Синдә типкән моңлы йөрәк
Миндә дә тибә бит ул.

Безнең әле йөрәк җитә
Җырларның ерагына...
Син булмасаң, мин булмасам,
Сөн бары елга гына...

Иделләр дә – елга гына,
Татар да – милләт кенә.
Идеаллар да – хыял гына,
Хыяллар – теләк кенә.

Без яшәдек. Каралмадык –
Җырлар булып таралдык.
Кемнәрнеңдер күңелендә
Моңнар булып калалдык.

Бәлки, шул моңнар әйләнер
Хыял канатларына,
Һәм күтәрер кемнәрнедер
Идеал тарафларына.

Уятырга бу халыкның
Җанындагы кузларын
Мин аз гына иртәләдем,
Син аз гына соңладың.

Безне күпләр туздырдылар,
Кемнәре соң уздырыр.
Бик уздырып та булмыйдыр,
Безнең җыр ул безнең җыр.

Без бүген дә күңелләргә
Җыр булып уралабыз.
Без көндәшләр булалмыйбыз,
Сөндәшләр бул ал абыз.

Мин сөенәм бу дөньяда
Синең дә булуыңа.
Син Сөннең Шагыйре инде,
Мин аның улы гына.

Дөнья сиңа да, миңа да
Буташтырды төрлесен.
Аралар өзелгәндә дә
Тоташтырыр безне Сөн.

МОҢ

(Хәния Фәрхи турында уйлап)

Син моң сибеп киттең бу дөньяга,
Төреп киттең якты өметкә...
Үткәннәрдә калган кебексең дә,
Киләчәктән көткән кебек тә.

Ул үткәннәр белән бүгенгенең,
Киләчәкнең моңы бер аның...
Бөтен моңын фани бу дөньяның
Берләштерә сыман җырларың.

Җанны кузгатырлык язмыш булып...
Күңел юатырлык моң булып...

* * *

Ә син көтмә аны беркайчан да
Майлар назы булган языңны...
Син күралмый калдың майлар назын,
Кайлардадыр язың абынды.

Абындымы, әллә азындымы,
Узындымы – нинди аерма.
Баерга дип барган кояшның да
Нуры чагыла бары каенда.

Ә мин, бәлки, шулай күренермен –
Каеннардан төшкән нур булып.
Кояш елмайганда – бик кечкенә,
Болыт дулаганда – зур булып.

Мин, язларым белән кочаклашып,
Җәйләрне дә уздым – сизмәдем.
Берни сизми кергән көзләремдә
Язлар белән тулы күзләрем.

Һәм мин көтәм аны элеккедәй,
Килер, кире какмас шикелле.
Ансыз миңа агымсулар акмас,
Алсу таңнар атмас шикелле.

Көз сукмагы буйлап атлап барам,
Өзелеп көткән ярсу язым юк.
Алсу таңнар ата – нурларым юк,
Агымсуда – минем агым юк.

Сыңар сукмак буйлап атлап барам,
Бу дөньяда ярый үзем бар.
Үзәкләрне өзәр көзем бар да,
Шул көзләргә түзәр түзем бар.

Ә син көтмә аны беркайчан да,
Майлар назы булган языңны...
Көзләреңә килеп җиталмады,
Кайлардадыр язың абынды.

БЕРГӘ ЙОКЛЫЙК

Сөеник тә шундый хаклык барга,
Бергә йоклыйк – бер үк вакытларда
Синең вакыт белән минем вакыт
Йокласыннар әле кочаклашып.

Синең урын белән минем урын
Беркайчан да, бәлки, бер үк булмас
Бер үк уйда йөзгән чакларда да
Бер үк сукмаклардан йөреп булмас.

Исәпләр дә вакытлыча гына.
Әйдә, икәү бергә йоклыйк әле
Сыеныйк та вакыт кочагына...

Ә без барыбер йоклый алмый идек,
И яндыра иде учаклары...
Бервакытта җәйгән кочакларның
Сагындырыр әле шул чаклары...

КИРӘКМИ

Туганым шикелле тибрәлә
Дөньяда иң таныш чалымнар...
Берегез бернигә кирәкми,
Мин сыздым сезне үз җанымнан.

Үзегез, хисегез, сүзегез
Күңелем кылларын тирбәтми.
Берегез беркемгә кирәкми,
Беребез беркемгә кирәкми.

Кешеләр өчен дип төзелгән
Җаннардан өзелгән дөньябыз...
Җаннардан өзелгән дөньяда
Мин ялгыз, син ялгыз, без ялгыз.

Моң иде күңелем, җыр булып түгелдем,
Сибелдем генә мин бу илгә...
Җырым да кирәкми, үзем дә кирәкмим,
И авыр барыбер күңелгә.

Мин беләм мондыйрак егетләр
Бу илдә тиз генә тумасын.
И килде минем дә кайвакыт,
И килде кадерле буласым.

Үземне бар иткән дөньяның
Җаныма җыйдым да назларын...
Мин сезгә җанымны калдырдым,
Мин сездән берни дә алмадым.

Кайвакыт тормышның бакчасын
Язмышның җилләре сирәкли...
Мин сезгә кирәкле булмадым
Һәм сездән берни дә кирәкми.
Кирәкми.

БЕР ҮБЕШҮ

Дәүләте дә чит шикелле.
Дөньясы да ят кебек...
Син генә үз – үптем әле,
Җир шарына яткырып.

И синдәге сихри ихласлыклар...
И синдәге серле ачылу...
Колач җәеп көнгә чыгуларың... –
Хәнияле бөек гасыр бу...

Син булганга гына бу тормышның
Тамырыннан әле моң агар...
Килеп кенә син дә киталмыйсың,
Синсез була алмый дөньялар.

Бу дөньялар меңгә әйләнер дә
Көннәребез көнгә күмелер.
Тик кешенең үз җырларын җирдә
Җырлаттыра торган төре бер.

Моң ул кала... Күңелләрдә кала,
Җанда эри, җанда югалмый.
Җиргә килеп күренгәнсең икән,
Бу җир инде синсез бул алмый.

Син әле дә яшисеңдер кебек
Күңелләрдә ташып, ургылып.

Синең хисләр белән минем хисләр
Бергә икән – бу бик төзек булмас...
Нәрсәләрдер төзеп булганда да,
Нәтиҗәләренә түзеп булмас.

Синең белән минем... Беләсеңме,
Уртак безгә бары вакыт кына.
Куенында аның ятып була,
Хатирәләр буйлап кайтып була.

Ходай безгә шул вакытны биргән,
Күңелдәге кузны болгатырга.
Сине уйлап мине кузгатырга,
Мине уйлап сине сызлатырга.

Бу вакытта бергә яшибез без,
Бар хисләрне вакыт аклаячак.
Урыннар ул урын килеш кала,
Ә вакытлар кире кайтмаячак.

Вакыт кына берәү...
Түшәкләр дә,

Мәдәни җомга
27 октябрь
№42, 2023

● Гайнан Кормашның бабасы Габделгазиз мулла яшәгән йорт.

Гайнан Кормашевның ачылмаган тарихы

Белешмәләрдә «Гайнан Нури улы Курмашев 1919 елның 27 февралендә Казахстанның Актүбә өлкәсе Новоалексеевка бистәсендә туган», дип язылган. Аның әти-әнисе Марий Элның Бәрәңге районы Куян авылыннан, Гайнан гаилә Казахстанга күчеп киткәч туган. Кайбер чыганаклар, шул исәптән авыл халкы фикеренчә, Гайнан Куянда туган, гаилә ул тугач күченеп киткән. Димәк, «Идел-Урал» легионындагы яшерен оешма җитәкчесе Гайнан Кормашев шушы яклардан.

1944 елның 25 августында Берлиндагы Плетцензее төрмәсендә фашистлар тарафыннан гильотинада җәзалап үтерелгән унбер җәлилченең берсе Гайнан Кормашев була. 25 яшьлек егет җәзаланучылар исемлегендә беренче урында тора.

Гайнан Кормашев Куян авылында укытучы, аннан соң Актүбәдә мәктәп директоры булып эшли. 1939 елда аны армиягә алалар, ул хәрби мәктәпне тәмамлый, фин сугышында катнаша. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк разведчиклар командиры була, аның ничек пленга эләгүе билгеле түгел. Ул дошман тылына махсус задание белән җибәрелгән була. Кайбер тарихчылар фикеренчә, Кормашев ул вакытта Германия җитәкчелеге тарафыннан оештырылган «Идел-Урал» легионына эләгү өчен махсус рәвештә әсирлеккә төшкән булырга да мөмкин. Ул легион советлар армиясенә каршы төзелгән була. Гайнан Кормашев татар легионында яшерен оешманы җитәкли.

Яшерен оешма хакында билгеле булгач, алар кулга алына. 1944 елның февраль аенда Дрезден шәһәрендә узган Империя суды карарында алар «Кормашев һәм тагын ун кеше» дип телгә алына. Хәрби мәхкәмә аларны, «дәүләткә каршы җимерү эше алып бару»да гаепләп, үлем җәзасына хөкем итә. Ул төркем тарихка «җәлилчеләр» атамасы белән кереп калган, чөнки төркемнең идеологик җитәкчесе итеп Муса Җәлил санала.

1990 елда Гайнан Кормашевка беренче дәрәҗәдә Ватан сугышы ордены бирелә. Авылдашлары фикеренчә, ул – Герой исеменә лаеклы каһарман.

Куянга без Мазарбашы авылы аша бардык. Мазарбашында туган якны өйрәнүче Наил абый Бариев каршы алды. Авыллар бер-берсенә терәлеп тора икән. Мазарбашының Ленин урамы бер мизгелдә Куян авылының Совет урамына әйләнеп куя. Урам буйлап тәзек, матур йортлар тезелеп киткән, төрле төстәге бизәкләр белән ясалган калай тәрәзә йөзлекләре еш очрый.

Яшел төсе уңа төшкән агач йорт янына килеп туктадык. Тәрәзә төбендә балчык чүлмәкләрдә яран гөлләре утыра, ап-ак пәрдәләр эленгән. Олырак яшьтәге хуҗабикә кулы сизелә. Хуҗабикә чыннан да олырак яшьтәге ханым булып чыкты, әмма бу йорт – китапханә икән, элмә такта шуны күрсәтә. Яңа гына җылыта башлаган кояш кагылган иске китапларның исе тагын да көчлерәк сизелә кебек. Җылыда изрәп киткән бүрәнәләр исе дә бар. Бүлмә тулы гөлләр. Түрдәге өстәл артында утырган китапханәче апаның башы гына күренеп тора. Мәсхүдә апа Бәйрәмова – Кормашевлар нәселенә бәйле кеше.

Гайнан Кормашевның әнисе ягыннан бабасы – Кормашев Габделгазиз, ә Мәсхүдә апаның әнисе өчен Гайнан өченче буын туган булган. Габделгазиз мулла балаларының метрикасын тутырганда, фамилияләрен Кормашев дип түгел, ә Газизов дип язган.

«Дөресен әйткәндә, мин аларга турыдан-туры кагылышлы буын була алмыйм. Мине әни тәрбиягә алган. Мине тапканда үземнең әнием үлгән, ай ярым хастаханәдә ятканмын, мине алучы булмаган. Бу гаиләдә бала булмагач, мине тәрбиягә алганнар», – дип аңлатты Мәсхүдә апа.

Мәсхүдә апаның туганнан туганы Ләлә Хәсәншина Казанда китапханәдә эшли. Ләлә апа белән телефоннан сөйләшеп алдык. Аның әтисе Җәүдәт абый (Габделгазиз мулла улы) күптән түгел генә вафат булган. «Әтигә кабер ташы куйганда Кормашев һәм Газизов фамилияләрен күрсәтергә телибез», – диде ул. Җәүдәт абый, шәҗәрәсе буенча, Г.Кормашев линиясендәге соңгы ир-ат булган.

Гайнан Кормашев шәхесенә килгәндә, Мәсхүдә апа аның тырыш кеше булуы турында кечкенәдән ишетеп үскән. «Безнең авылдан чыгу белән горурланабыз. Бик әз яшәгән шул. Хыяллары бик зур булгандыр, балалары булыр иде, дип уйлыйсың. Ул шигырьләр дә язган. Шул шигырьләрне бер җыентык итеп чыгарсыннар иде», – ди ул.

Гайнан шул шигырьләре аша Муса Җәлил белән танышып киткән дә инде. Ул үзенең шигырь дәфтәрләрен күтәреп, аның янына барган була.

Мәсхүдә апа кырык елдан артык китапханәдә эшли. «Халык газета-журналларга күбрәк игътибар бирә, тик алар күп килми шул. Балаларга журналлар, олылар арасында тарихи китапларны алучылар бар», – ди.

Без клуб мөдире Илдус абый Газимов белән киттек. Клуб бинасы китапханә күршесендә генә. Шундый ук яшел төскә буялган агач бина. Ишектән керүгә мич, дивар буйлап гөлләр тезелеп киткән. Клубтагы пөхтәлектә хатын-кыз кулы сизелә. Илдус абый белән бергә Миләүшә апа Шәрәфетдинова эшли. Ул безне үз өендә чәйгә көтеп тора иде.

Хуҗабикәнең тәрәзә төбе дә миләүшә чәчәкләренә күмелгән. Миләүшә апа өйдә үзе генә иде: иптәше Мәскәүдә вахтада, балалар укый.

Бу як авылларда ат асраучылар күп икән. Чит җиргә барганда кыстырып бара торган күчтәнәч – казылык. Аның тәме ясау технологиясеннән генә түгел, атны ничек ашатудан да тора икән. Бик нечкә итеп кисә белү дә зур осталык. Казылык ясаучылар Мазарбашы авылында күп булу сәбәпле, мәзәге дә бар икән.

– Атка атланып, җир тирәли сәяхәт кылып буламы?

– Була-була. Мазарбашында атыңнан казылык ясамасалар...

Миләүшә апалар янында гына Габделгазиз мулланың нигезе. Ишегалдында ул утырткан агачлар утыра. Ә Гайнан яшәгән нигезнең кайда булуын төгәл генә әйтә алучы юк.

«Авылда Гайнан Кормашны белмим, дип әйтүче булмас. Аны бөтенесе дә белә, ул исем бөтен кешенең аңына сеңеп калган. Зур батырлык күрсәткән кеше бит. Гомумән, авыл баласы югалып калмый ул», – ди Миләүшә апа.

Шуны да сиздем: биредә безнең сөйләм аерылмый. Үземнең – Тәтеш ягы кешеләре белән

● Гайнан Кормаш.

● Дания Габбасова.

сөйләшкән кебек.

Миләүшә ападан чыккач, Габделгазиз мулла йорты янына бардык. Йорт боегып утыра. Капкага сукмак салынмаган, өй алдындагы коймага кадәр кар өелгән. Йорт каршында су ала торган колонка бар, суга килүчеләр бар ахрысы, сукмак тапталган. Гомумән, андый колонкалар урамнарда еш очрый. Алар янгыннан саклык чарасы буларак куелган.

Мәктәп өч катлы. Каникул вакыты булгач, тып-тын. Гомумән, балалар анда укымый әле, чөнки мәктәптә ремонт башларга җыеналар. Балаларның бер өлеше Мазарбашы мәдәният йортына, бер өлеше Куян балалар бакчасына укырга йөри. Укучыларны автобус йөртми.

Ишек янында Гайнан Кормашев сурәте белән такта эленгән. Бизәкләп ясалган пыялалы ишекләргә бәрелгән кояш нурлары төрле төскә кереп тарала. Вахтада утыручы апалар укытучылар икенче катта, диде. Диварларда да милли бизәкләр ясалган.

Директор урынбасары Земфира апа Габдуллина янына кердек. Мәктәптә йөзгә якын бала укый, Земфира апа үзе утыз елга якын бу мәктәптә эшли.

«Мәктәп Гайнан Кормашев исемен йөртү белән горурланабыз. Безнең балалар оешмасы да аның исемендә. Мин башта оештыручы-педагог булып эшләдем, бик күп чаралар аның белән бәйле иде. Чараларны зурлап оештырабыз. Гайнанның укучыларын очрашуга чакыра идек. Хәзер алар юк шул инде. Алар үрнәге булганда тәрбия башка иде. Хәзер инде алай киң итеп эшли алмыйбыз, балаларны музейга алып керәбез, дәресләрдә өйрәтәбез. Без дә олы кешеләрдән ишеткәннәрне генә беләбез. Авыл халкы Гайнан белән горурлана. Бездә халык татарлыкны күрсәтү теләге белән янып яши», – ди Земфира апа.

Мәктәпнең өченче катында музей бар. Ремонт мень-мень башланырга торса да, аны әле җыймаганнар. Музейда авылдан җыелган борынгы әйберләр саклана. Салам түбәле авыл йортын да күрергә була. Әлбәттә, Гайнан Кормашев почмагы бар. Анда истәлекле альбомнар, фотолар, документларның күчерелмәсе. Бер почмактагы киштәгә конвертлы хатлар куелган. Аларның адресларына күз төшерәм. Казахстан, Актүбә, Татарстан, Мөслим районы... Бу хатлар кемнән, дип сорагач: «Бездә татар теле укытучысы булып эшләгән Фәйрүзә апа Кормашевның туганнары белән хат алыша иде», – диделәр. Фәйрүзә апа ул көнне мәктәптә юк иде, телефоннан шалтыраттым.

«Алар – туганнары түгел, Гайнан Кормашев белән кызыксынган укучылар, мәктәпләрдән килгән хатлар. Мин аның сеңлесе Дания апа белән элемтәдә тора идем. Ул вафат булгач, өй телефонын алучы булмады. Туганнары арасында ул Куян авылында туган диючеләр дә бар иде. Казахстанга чыгып киткәндә яңа документлар ясатмадымы икән дип тә уйладык. Мин аны ачыклый алмадым. Гайнан Кормашев исән калган булса, тарихның бик күп өлеше икенче төрле булыр иде. Ул бик төпле, тирән белемле ия, 19 яшендә үк мәктәп директоры булып эшләгән. Үзе математика физика укытучысы булса да, әдәбиятка якын торган, җор телле, шаян булган.

Гайнан Кормашев бәхетле булгандыр дип уйлыйм. Ул вакытта кеше өчен бәхет төшенчәсе хәзерге мәгънәдә кабул ителмәгән. Туган илне яклау – бәхет. Алар туган ил өчен яшәгән. Патриотик тәрбия бик көчле булган.

«Гайнанның шундый булуында авылның роле дә бик зур булгандыр. Авыл мәктәбен республикада «кузница кадров» дип йөрткәннәр иде. Әшне намус белән эшли торган тырыш кешеләр чыккан бездән. Гайнан Кормашев исеме югала торган түгел», – дип сөйләде Фәйрүзә апа.

Без күршедәге Портчара авылы имамы янына да кереп чыктык. Ул авылның документларда теркәлгән беренче исеме бик кызыклы булган – Пикса Кугуэнер другого усаду. Наил абый шулай дип сөйләде. Чучарма дигән исеме дә булган әле.

Авыл имамы Равил Шәрәфетдинов шулай ук Кормашевлар нәселенә кагылышлы кеше. Бик ерак туган булып чыга. «Кормашевлар – лидерлар нәселе», – ди ул. Үзен дә очраклы рәвештә генә имам итеп сайламаганнардыр дигән фаразы да бар.

«Кормашевларны ике төркемгә бүлеп карарга кирәк, бер як – гыйлемле, икенче як эшмәкәрләргә бай булган. Безнең бабайлар эшмәкәрләр булган. Әнинең дә бу авылда дәрәҗәсе булды. Ул гел башкача киенде, әни урамның уртасыннан йөри иде. Үзләрен күрсәтә белү Кормашевларның канына салынгандыр. Әни кешедән куркып яшәмәде. Әни тырышлыгы белән бервакытта да төшеп калмаганбыз. Гайнан Кормаш та курка торганнардан түгел, лидер булган. Безгә аңа кадәр ерак әле. Андый рухлы кешеләр хәзер дә бардыр, без аларны соңыннан гына таныйбыз шул», – дип сөйләде ул.

Наил абый да ул нәселне күп өйрәнгән кеше. Бик күп туганнарына чыккан. Ул Кормашевларның туганнарын бергә җыеп, зур очрашу ясарга хыялланa. «Кайберләре үзләренең Кормашевлар нәселеннән булуын белми дә. Документларны өйрәнгәч, кешеләргә килеп әйтәм дә, аптырап калалар», – ди ул.

Гайнан Кормашевның эшчәнлеге, торган җирләре, нәселе өйрәнелә, ә мәхәббәт? Сөйгәненә булган мәхәббәте? 24 яшьлек егет яраткан бит. Ул Дания Габбасова исемле кызга атап шигырьләр язган. Сөйгәне аның хатларын көтеп алгандыр... Дания апа гүр иясе инде. Наил абый аның белән аралашкан, тик бер тапкыр да ул темага сөйләшмәгәннәр. Шаккаттым. Тарихчылар коры фактларга, документларга, архивларга таянып эшли шул. «Мин аны күптән түгел генә аңладым. Нишләп сорамаганмын? Күңел кылларына тияргә курыктыммы икән? Ул бит бик нечкә тема. Минем өчен зур үкенеч булып калды», – ди Наил абый.

Үзем яшь булганга, бу тема миңа мөһим кебектер, бәлки. Шуңа Дания апаның кызы Луиза Сафинаны эзләп таптык. Луиза апа, әниегезнең аның турында сөйләгәне булдымы, дим.

«Беләсезме, ул шундый: яшергәннәр, курыкканнар. Әни сөйләми иде. Әти дә булгач...

Сиксән ничәнчедер елларда җәлилче Фәрит Солтанбәков әнигә үзенең китабын алып килгән иде. Әнигә розалар бәйләмен дә тапшырды. Мин шул китаптагы истәлекләрдән генә алар турында белдем. Әни дә, Гайнан Кормашев та – 1919 елгы. Шулай килеп чыккан – әни педучилищеда аны укыткан да әле. Казанда педагогия институтында укыганда очрашканнар. Әни Кормашевка үзенең фотосын биргән. Кормашев шуны үзе белән алып киткән. Кормашевның әнигә язган хатлары сакланмаган. Бәлки, ул дуслыктан чыккан романтик мәхәббәт булгандыр. Әни 2001 елда вафат булды. Ул гомере буе укытучы булып эшләде. Бик белемле, акыллы кеше иде», – дип искә алды Луиза ханым.

Фәрит Солтанбәков хатирәләрендә: «Дания: «Мин сине яратам, көтәм, гомерем буе яратырмын», – дип язган», – диелгән.

1950 нче елларда Дания Габбасова Александр Кузнецов исемле керәшен белән гаилә кора. Ире ятимнәр йортында тәрбияләнгән. Үзләре исә дүрт бала үстергәннәр.

Фәйрүзә ападан да сораштырдым. Дания апаны мәктәпкә очрашуларга да чакыра торган булганнар.

«Элек ул мәсьәлә турында кычкырып сөйләү юк иде. Ул балаларга бер-беребезне яраттык дип сөйләп тормый ич инде. Бергә укыдык, ул яхшы укыды, дип сөйли иде. Хисләр турында сөйләшүләр булмаган. Бу – татар хатын-кызына хас сыйфат. Хатын-кыз ир кеше турында шапырынып сөйләми, үз ире дә бар бит. Мин дә мин дә үземне аның урынына куям: нәрсә дип әйтер идем – шуны гына. Олы кеше яшьлек хисләрен сөйләргә яратмый», – диде ул да.

Гайнан Кормашевның мәхәббәте темасы минем өчен ачылып бетмәгән булып калды...

Гайнан Кормашевны читләп узган тагын бер мәсьәлә – Герой исеме. Гайнан Кормашевка Герой исемен бирдертү өчен район башлыгы Әлфит Ибраев күп көч куеп караган, нәтиҗәсе генә булмаган

«Без моннан ун ел элек ике тапкыр Мәскәүгә документлар җибәрдек. Мәскәүдәге профессор Абдулхан Әхтәмҗанов язган хат та бар иде, анда яшерен оешма җитәкчесе Гайнан Кормаш булган, диелгән. Ул журналга язма да бастырып чыгарган иде. Бер җавап та килмәде. Белмим, бөтен материалларны туплап, тагын бер тапкыр язып карасак кына инде. Туганнары ул эшкә керешми, алар гади. Тагын бер җиң сызганып карасаң була, әмма өмет юк диярлек. Ул Герой исеменә лаек дип саныйбыз. Ул бик зур эш башкарган, ять-яшь көе зур батырлык күрсәткән. Без документларны администрация исеменнән җибәргән идек, әле уйлап торам, әллә аның исемен йөрткән мәктәп исеменнән җибәреп карарга мы?..» – ди җитәкче.

Бөек Ватан сугышы музей-мемориалының өлкән фәнни хезмәткәре Михаил Черепанов сүзләренчә, герой исемен бирдертү өчен мөрәҗәгать туганнары тарафыннан язылырга тиеш.

«Район җитәкчесе Герой исемен бирү өчен тырыша, тик Кормашевның туганнарыннан башка ул эшне башкарып булмый. Бүләкләү бүлегенә алар обращение язарга тиеш. Ерак туганнарын табып бетерергә кирәк. Минемчә, Кормашевның ерак туганы Сания Газизҗанова мөрәҗәгать итәргә тиеш. Ул – аның биографиясен өйрәнүче иң актив кеше. Без аның белән бергә Гайнан Кормашевның яшерен оешмадагы эшчәнлеген өйрәнәбез. Бергә Подольскидагы архивка бардык. Гади офицерлар, сержантлар исемлегендә Кормашев та, аның иптәшләре дә юк. Димәк, алар башка хезмәттә булган. Шуның өчен аның турында конкрет документлар юк. Ул – югары дәрәҗәдәге разведчиклар кебек яшерен архивта. Без аның белән бергә булган якташларын таптык. Хәзерге вакытта Кормашев белән бергә булган легионерлар турында материал әзерлибез.

Г.Кормашевның шәхесенә җитәрлек дәрәҗәдә игътибар бирелми. Бөтен разведчикларга да шулай. Без барысының да исемнәрен, батырлыгын дә белеп бетермибез. Г.Кормашев кылган батырлыкның мәгънәсен киләчәктә генә аңларбыз. Аның шәхесенә, эшчәнлегенә тулы бәя бирелмәгән әле. Ул яшерен оешма җитәкчесе булган, Җәлилдән присяганы да ул кабул иткән».

Гайнан Кормашев белән бәйле, аның шәхесе белән кызыксынган кешеләр белән аралашкач, һәрберсе аерым эшчәнлек алып бара, әмма кыйбла бер түгел сыман тоелды. Авылдагы туган якны өйрәнүчеләр, шәһәрдәге туганнары, район администрациясе арасында элемтә юк кебек. Бәлки, чыннан да, башта Кормашевлар нәселен бергә җыярга кирәктер…

Куян авылыннан башланган сүз иде ич. Авыл халкы исә бик гади. Авыл төзек, зур, сирәкмирәк кенә ташландык йортлар очрый. Гайнан Кормашев исеме дә халык телендә, хәтерендә, аңында саклана.

Гөлүзә ИБРАҺИМОВА.

Мәдәни җомга
27 октябрь
№42, 2023

ТЕЛӘКӘЙ ЧИШМӘСЕ

Вахит ИМАМОВ

Бәрсуан елгасы буендагы Казый мәчете – Агыйдел, Өфе, Дим вә Әй елгалары буенда яшәгән барча мөселман өчен истәлекле һәм дә изге урын. Уфа, Минзәлә, Бөре вә Бәләбәй тирәләрендә, яисә Уфа белән Казан арасындагы барча олысларда яшәүче, авыллар тотучы барча старшиналар вә ил агалары һәр ел саен диярлек шунда җыела торган изге бер гадәт бар. Анда иң танылган сәет вә ишаннарның Коръән шәрифтән сүрә вә вәгазь укуларын гына тыңлап калмыйлар, мөселман халкына падишаһ галиҗнаплары төшергән фәрманнарны, алдагы мәгыйшәттә булачак үзгәрешләр белән дә танышалар иде. Шунда ук барча олысларга җиткерелгән салым күләме дә тикшерелә, хөкүмәт ниндидер елга өстендә күпер төзү, кайсы кирмәннәр арасында киңәйтелгән юллар күтәрү өчен ирләр вә олаулар, гаскәргә дип сайланган яу атлары, көбә яисә шайман (сугыш киеме яки хәрби корал) таләп итсә, андый йөкнең барчасын старшиналар арасында бүлешәләр иде. Кайсыбер елларда Уфа белән Казан арасындагы авыллардан җыеп, аерым алай вә нөгәрләр (полк һәм отряд) озату турында да фәрман төшерделәр. Шундый бер фәрманнан соң Теләкәй морзаның да ун ел чамасы элек Кырым татарларына каршы яуга китеп, андагы бер кылыч орышында сыңар күзле пәһлеван белән алышка чыкканы да булды...

Көтмәгәндә килеп чыкты ул хәл. Теләкәй үзе белән алган өч аргамагының берсе янында буталып калган иде. Атның бәкәл асты юлда ниндидер ярык таш яисә такта арасына сыдырылып шешкән дә үлекли үк башлаган. Көтүче һәм пешекчеләренә генә ышанмыйча, Теләкәй шул аргамакны чатырлар корылган аланлыктан читкә алып чыкты да, туснаклар (хәерче, ялланып көн күрүче) йөгән вә ялларыннан тотып торган чакта, пычак белән сызып, бәкәл астындагы шешне ярып җибәрде, ә аннары инде атны биетә-биетә, җыелган бар үлеген тышка сытып чыгарды. Соңыннан җәрәхәт өстенә күп итеп көл сипте, аю мае сөртте. Менә шушы бәладән котылганнан соң гына ул алыш булачак мәйдан түренә атлап узган иде. Караса, сыңар күзле пәһлеван ниндидер урыс укчысын аркан ташлап кармакка эләктергән дә, ияренә таккан корбанын үкертә-чината, үз гаскәре ягына өстерәп бара.

– Әй, син, Салам торхан! Бергә-бер алышны синең кебек аркан ташлап уздыралар мыни? Йөзгә-йөз килеп орышырга кодрәтең җитмиме? – дип оран салды Теләкәй улчагында.

Тугандаш халык морзасының гөбедән чыккандай яңгыравык тавышын сыңар күзле пәһлеван да ишетми калмады. Ул кырт борылып, әрсез дошман ягына исән калган күзен төбәде дә, ихахайлап көлә-көлә, Теләкәй өстенә үт әчесен койды.

– Ә син, кәрлә, мине акылга утыртырга җөрьәт итәсеңме?

– Син чебеш кебек өтек урыс укчысын түгел, менә миндәй карт имәнне тамырыннан кымшатып кара, – дип Теләкәй инде мәйдан уртасына атылып та чыкты.

Кырым пәһлеваны кулындагы арканны ычкындыруга ук әсир урыс укчысы тиен кебек кенә итеп элмәктән ычкынды да, күз ачып йомган арада үз сугышчылары арасына чумып юк булды. Җирле пәһлеван кәрлә дип кимсетергә маташса да, Теләкәй буйга чынында да әлләни зур түгел, әмма җиргә йөзәрләгән тамыры белән ябышкан имәндәй нык иде. Җайдаклар бер-берсенә каршы чаба башлауга ук Теләкәй кулындагы имән чукмар белән сугып, Кырым пәһлеванын иярennән очырып төшерде. Теге ис-зиһенен җыйган арада Теләкәй аның бугазына кыска саплы сөңге угын китереп терәде, аннары шук малайга сабак биргән хәлфә тавышы белән соңгы сүзен әйтте.

– Мин монда үз туганымның башына җитәргә дип килмәдем. Мине яу сәфәреннән котылып кала алмау мескенлеге, чарасызлык куып китерде. Кырымлыларның бездәге татарга да, башкорт илә чирмешкә дә зыян салганы юк, мин дә зәүрәт салмыйм. Иллә мәгәр орыш-яулар кузгаласы булса, миндәй кәрләдән ерактарак йөр, яме, туган...

Молоствов атлы полк башлыгы мондый сатлык орыш остасын соңыннан үз янына чакырып пешермәкче булган иде дә, каршында ике як җилкәсенә дәү-дәү ирләрне утыртып әйләндердерәй Теләкәйне күргәч, кул гына селтәде.

– Русского стрельца спас от неминуемой смерти, за это тебе огромная благодарность...

Соңыннан теге урыс укчысы аны үзе эзләп килде.

– Ул сукыр төрек мине үз лагерьларына алып чыгуга ук суеп үтерер, дип шыр җибәргән идем, ярый син коткардың.

– Каян килгән төрек микән соң ул, ничек уйлап таптың, кем котыртты? – дип Теләкәй бар ачуы белән инде моның өстенә ябырылган иде, бичара укчы аптыраудан үзе дә җебеп төште.

● Иван Алексеевич һәм Пётр Алексеевич.

– Сың, монда бөтен бояр вә кенәзләр безне «кырымлылар төрек янычарларын яллаган, алар үзләре генә безнең өч-дүрт полкка да каршы тора алмый», дип гелгел котырта бит. Чынлыкта мин төрек белән кырым татарын да, хәтта сине дә кырымлылардан һич аера алмыйм.

Беркадәр тын алганнан соң гына янә кулын сузды.

– Миңа үз укчыларым янына кайтырга вакыт. Алай-болай булса, ярдәмгә атлыгу өчен хәзер минем чират.

Аннан өстәп куйды:

– Коры кул белән килгәнгә гаепләмә инде. Мөгаен, кирәгем дә чыкмас. Әмма барыбер белеп кал, минем исемем Федор.

Теләкәй кул сузды.

– Ә мин Теләкәй морза. Хәер, синең өчен морза түгел инде...

Гаҗәп, улчакта яу сәфәрендә шактый озак айлар йөрделәр, ә укчы Федор бүтәнчә бер дә күзгә чалынмады...

* * *

Уфага төбәп юлга чыгуга ук, Чәрмәсән елгасы буенда төн кунарга тукталгач, Теләкәй морза җитәкләгән нөгәргә Чакмагыш, Бүздәк белән Тәтешле яугирләре килеп кушылды.

– Нинди җәдид фәрман икән соң ул, берәр озынколак аның турында хәбәр китереп ирештермәдеме? – дип сорашырга ябыштылар.

– Без дә сезнең кеби гади инсаннар шул, - дип гәрәйлеләр дә иңбашларын сикертеп куярга мәҗбүр булды...

Казый мәчете Уфага җитәргә ике фәрсах ара якынрак урнашкан. Гәрәй, Елан, Байлар олысларыннан кузгалган җайдаклар килеп җиткәндә Бәрсуан елгасы буендагы уйсулыкны дистәләгән чатыр каплап алган иде. Гади яугирләр һәм туснак көтүчеләр хуҗалар өчен чатыр кора башлады, ә Теләкәй морза камчысын итек кунычына кыстырып кына, өлгерәк аксакаллар белән күрешергә китте. Себер юлындагы Бүләкәй олысыннан ук кузгалган ахун Сәгыйт Җәгъфәр хәзрәтне Теләкәйнең инде дүрт-биш ел чамасы күргәне юк иде, билгеле, янына килеп җитүгә үк аны кочагына алды.

– Ихтирамым чиксез сиңа, шанлы Җәгъфәр углы. Ходай тәгалә үзеңне ярдәменнән генә аермасын.

Сәгыйт хәзрәт Теләкәй белән бергә теге вакытта Кырым походына да барган иде. Анда ахун булып йөрде, әмма төнге учак тирәсендә моңланып утырган чагында тезгән сүзләре дә үтә сәер вә әрнүле иде.

– Казан каласын аяк астына салып, барча болгар-татар җирләренә хуҗа булып алгач, мин ошбу кәферләрне безнең халыкны талаудан туктар, адым саен күзебезгә төртеп, ата-бабаларыбыз үз иреге хакына алып барган җан саклау яулары өчен үч алмас, динебезне рәнҗетмәс, тулаем әйткәндә, безне үз тиңедәй күреп гомер итәсенә өмет баглый идем. Безне, болгар-татар халкын, шулар «бүре баласын бүреккә салсаң да, ул урман ягына карый», дип мыскыл иткән була. Ә үзләре чүл бүресеннән дә гожрак, тиреңне генә түгел, сөякләреңне дә калдырмый...

Казый мәчетендә уздырылган намазларның берсен шушы Сәгыйт хәзрәткә тапшырдылар. Ә мәчеттән чыксалар, Уфа каласыннан инде дворяннар да килеп җиткән. Арада Теләкәйгә бик күптәннән таныш бояр Молоствов та бар. Ун ел элек Кырым походына шуның кул астына басып барганнар иде бит, бернинди җиңүгә дә ирешә алмыйча, көзге яңгыр астына эләккән чебеш көтүе урынына куып кайтардылар. Ә хәзер, әнә, Молоствов түрә койма өстенә менеп кунаклаган күркәгә тиң. Якасы чәшке тирәләре белән каймаланган затлы җиләнгә төренгән. Кулында ап-ак бишбармаклар, асылташлар белән бизәлгән көмеш таяк. Аягы тузанга батмасын йә таеп китмәсен, дигәннәрдер инде, ул килеп туктаган көймәле арба белән калкулыктагы биек мөнбәр арасына кызыл келәм дә җәеп куйганнар бит.

Молоствов – воевода түгел, аның иң төп ярдәмчесе генә. Воевода үзе вакланмаган. Ул юк икән, димәк, мөселман старшиналары һәм морзалар алдында Молоствов – иң зур түмгәк. Ниндидер бер укчылар сибае (офицер) мөселманнарны кисәткәннән соң гына, җыен мөнбәренә шушы түрәне чакырып чыгардылар.

– Мин сезнең бик күбегез белән Кырымга кадәр сузылган яу походын кичтем, сезнең нинди батырлар токымыннан икәнлекне үз күзләрем белән күреп беләм, - дип татар, башкорт, мари, чуаш старшиналарының салпы ягына салам кыстырудан башлап җибәрде ул. – Менә өч ай элек илнең мәркәзендә бөек падишаһыбыз Алексей Михайловичтан соң аның урынына тәхеткә утыртылган угылы Федор Алексеевич та көтмәгәндә, егерме яшендә вафат булып куйды. Мәрәсим атналарыннан соң боярлар думасы тәхетне мәрхүм Федор Алексеевичның бертуган энекәшләре Иван белән Петр Алексеевчларны тапшырырга карар кылды. Ошбу тарихи җиде мең дә өч йөз туксанынчы елның (юлианча 1682 ел) егерме алтынчы июнь көнендә генә, менә, бертуганнарның икесенә дә Мәскәү Кремленең Успенья соборында изге таҗ кидерделәр. Падишаһларыбызның икесе тиң рус дәүләтенә тугры хезмәт итәргә ант китерде.

– Нишләп бер тәхеттә ике патша соң ул? Ошбу гамәл бер хатынның күңелен ике ир чиратлап күргән шикелле була лабаса ул, – дип Йәнәй олысыннан килгән старшина үзалдына сөйләнгәйдәй кыбырсып алган иде дә, тавышының гайрәтен чамалап өлгермәгән, ахры, сүзләре дилбегә буе ераклыкта торган ирләргә дә ишетелерлек булып яңгырады. Байтак ирләр җиң очларына гына пырхылдап көлеп алды, мөнбәрдәге хуҗа үз тавышын яман кырыслатты.

– Мәрхүм падишаһыбыз Федор Алексееч гел-гел чирләп торгач, авыл туфрагы җиңел булсын, яңа җирләр яулау ниятеннән бер генә әрсез күршебезгә каршы да сугыш алып барырга җөрьәт итмәде, нәтиҗәдә ил казнасы таба өстедәй такыр хәлдә торып калды. Шул сәбәпле яңа падишаһларыбыз олы гамәлләргә кузгалырдай мая туплау өчен, иксез-чиксез илебез биләмәләренең бер өлешен чиркәү вә монастырьлар карамагына бүлеп бирергә мәҗбүр булды. Иван Алексееч белән Петр Алексееч галиҗнапларенең изге фәрманы Казан илә Уфа воеводалыкларын да урап үтә алмый. Ошбу олуг фәрман буенча, Чулман белән Агыйдел буенда да яңа монастырьлар барлыкка киләчәк, моңача падишаһларның кулы килеп җитә алмаган берничә салада изге чиркәүләребез калкып чыгачак...

(Ахыры киләсе санда)

(Дәвамы. Башы 41 нче санда).

Герой исеменнән мәхрүм калган 7 татар

Галимов Михаил



Ул 1915 елда туган, 1941 елның 15 октябрендә Мамадыш комиссариаты аша фронтка чакырылган. Смоленск һәм Сталинград өчен яуларда катнашкан. Өч тапкыр яраланган. Дошман ягыннан «телләр» алып кайткан өчен 3 нче дәрәҗә Дан һәм Кызыл Йолдыз орденнары, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән. Ул 79 нчы гвардия укчы дивизиянең 80 нче полкындагы разведка ротасында хезмәт иткән.



1944 елның 1 нче августында ул беренче булып Висла елгасын кичеп чыга һәм туктаусыз ут астында дошманның берничә ут ноктасын, 15 ләп солдатын юк итә. Дүрт көн үтүгә, 5 августта якташыбызны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итәләр, аны раслап 8 нче гвардия армиясенең командующие генерал-полковник В.Чуйков та үз тамгасын сала. Ләкин татар героен 1945 елның 24 мартында Ленин ордены бүләкләп хуш итәләр.



Гайнуллин Сәлим Солтан улы

Ул Алтай краеның Калман районында 1924 елда туып үскән, фронтка 1943 елда Татарстанның Норлат район комиссариаты тарафыннан озатыла. 1 нче Белоруссия һәм 1 нче Украина фронтларында яу йөри, 3 нче гвардия армиясенең 218 нче укчы дивизиясендәге 667 нче полкында 3 нче батальонның танкларга каршы отделение командиры булып хезмәт итә, кече сержант.

1944 елның 19 июлендә Буг елгасын кичкәндә үз батальоныннан беренче булып танкка каршы ата торган мылтык белән дошман позициясенә бәреп керә, аларның 3 пулемет расчетын юк итә. Гранаталар ташлап, янә 15 немец солдатын сафтан чыгара. 1944 елның 30 июлендә Висла елгасын кичкән вакытта да аларны тоткарларга маташкан 3 немец мәргәнен юк итә. Биредә дә дошман траншеяларына үтеп, гитлерчыларны автомат уты белән кырып сала. Үзе яраланса да, сугышчан позициясен ташлап китми. 1944 елның 2 августында командование тарафыннан Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, ләкин әлеге бичара татарга да Кызыл Байрак ордены белән чикләнергә туры килә.





(Дәвамы киләсе санда).

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.

«Миллиард татар» челтәреннән. **Вахит ИМАМОВ** тәрҗемәсе.

ЗИФА БАСЫЙРОВА һәм

Казанда җырчы һәм театр актрисасы, ТАССРның атказанган артисткасы Зифа Басыйрова истәлегенә мемориаль такта ачылды. Мемориаль такта җырчы яшәгән йорт диварына – Казан шәһәре, Татарстан урамы, 16/78 йорт адресы буенча урнаштырылды.

Мемориаль такта ачу чарасын Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе Татарстан Мәдәният министрлыгы белән берлектә оештырды. Чараны Татарстанның халык артисты Фердинанд Сәлахов алып барды.

– Зифа Басыйрова исеме татар халкы өчен бик якын, ул аның каныңда, җанында яши. «Әллүки», «Зиләйлүк», «Әҗе көе», «Кара урман», «Уел»... Бу җырлар Зифа апа исеме белән телгә алына, буыннан-буынга күчеп, милләтебезне барлый, җырлата, елата. «Илем нинди газаплар күрсә, мин шул газапларны күрдем», – дип әйтә ул. Революция еллары, Бөек Ватан сугышы еллары, ачлык, ятимлек, сәхнәгә килү, театр сәхнәсе, эстрада сәхнәсе, танылу һәм мәңгелеккә күчеш...

Зифа Басыйрова 1910 елның 4 июлендә Мөслим районы Мөслим авылында дөньяга килә. Зифа апаның әти-әнисе дә бик матур җырлый торган кешеләр була. Әнисе Фәрхинур апа хәтта курайда да уйнаган. Кечкенә Зифаның моңлы булуын күреп: «Бу бала йә гомерсез була, йә бәхетсез була», – дип юрыйлар. Тик ачлык елларында Зифа апаның әүвәл әтисе Җәмил, аннары әнисе вафат була. Тома ятимә калган Зифа апа 14 яшенә кадәр балалар йортында тәрбияләнә. Аннан соң гына, туганнары табып, аны алып китә. Зифа апаның җырлаганын күреп, комсомол комитетлары татар-рус телләре курсларына укырга Казанга алып китәләр. Зифа апа театр техникумында укый. 1936 елда техникумны тәмамлагач, Г.Камал исемендәге театрга эшкә килә. Ул анда 20 ел хезмәт итә. 1930 еллар ахырында аңа Муса Җәлил, Салих Сәйдәшев белән эшләргә туры килә. Зифа Басыйрова студент елларында, беренче курстан ук, сәхнәдә драма актрисасы булып массовкаларда эшли башлый. Аңа кыска-кыска рольләр бирәләр, ләкин Хәбибулла Фәтхуллинның «Кузләр» пьесасында Рәисә роле уңыш китерә. Ул Г.Камалның «Хафизәләм, иркәм», Таҗи Гыйззәтнең «Чын мәхәббәт», «Изге әманәт», «Биш бүләк» музыкаль спектакльләрендә төп рольләрне

башкарып, халык күңеленә кереп кала. 1955 елда Татар дәүләт филармониясенә җырчы буларак кабул ителә. 1964 елга кадәр шунда хезмәт кыла. Аның башкаруында «Агыйдел каты ага», «Басыйр җыры», «Хуш, авылым», «Тургай җыры», «Дөм-дөм», «Мөслим», «Су буйлап» һ.б. җырлар татар музыкасының алтын фондын тәшкил итә. Тик «өстән» фәрман булгандыр, аны җырлатмыйлар.

Музыка белгече Клара Таҗиева: «Су буйлап» җырын бик күп җырчылар башкарды, әмма Зифа Басыйрова кебек бу җырны беркем дә башкара алмады. Бу – эпоха җыры», – дип искә ала. Чынлап та, су агышы – язмышлар агышы. Милләтнең күргән хәсрәте, кайгысы, шатлыгы. Һәм ул «Су буйлап» дигән җырында Зифа Басыйрова тавышында ишетелә.

Истәлек тактасын ачу тантанасына Зифа Басыйрованың туганы Альянаст Хәмидуллин да килгән иде. «Әнинең әтисе белән Зифа апаның әтисе – бертуганнар. Зифа апаның улы Рафаэль абый Хәсән Туфанның кызы Гөлгенә апага өйләнгән иде. Рафаэль абый белән Гөлгенә апа Тимур һәм Эдуард исемле уллар үстерде. Зифа апаның тагын бер сеңлесе Әлмәттә яши», – дип сөйләде ул.

Зифа апаның ире Гений Республиканец – сукбай (беспризорный) малай. Аның ата-анасы бик иртә ачлыктан үлә. Өч яшьлек малай Казан урамында бер кешесез ялгыз кала. Кемдер аны балалар йортына илтеп бирә. Исеме ничек? Атасы кем? Беркем белми. Менә шунда, балалар йортында табылдык балага исем кушыла. «Исеме – Гений, фамилиясе – Республиканец булсын». Татар баласы булуын чамалап, этисенең исемен «Измайлович» дип язалар.

Озакламый бу балалар йорты таратыла. Гений Республиканецны Беренче укчы татар полкы үзенә балалыкка ала. Ул шунда тәрбияләнә, мәктәпкә укырга йөри башлый. Ниһаять, полк улы Гений, югары белем алып, зур тормышка аяк баса. Башта ул Татар академия театрының директоры булып билгеләнә. Анда берничә ел эшләгәч, Гений Измайловичны Татарстан культура идарәсе башлыгы итеп тәгаенлиләр.

● **Гений Республиканец.**

1936 елда Казанда Ленинның мемориаль музеен оештыру мәсьәләсе күтәрелә. Бу аеруча җаваплы һәм әһәмиятле эшне – музей оештыруны – кемгә тапшырырга соң? Шоба Республиканецка төшә. Чөнки ул башка оешмаларда да үзен оештыру эшләренә сәләтле, армый-талмый эшли белүе белән танытклан була. Гений Мәскәүгә Надежда Константиновна янына китә. Владимир Ильичның гомер юлдашы Республиканец кандидатурасына бик риза булуын белдерә һәм мөмкин булган кадәр ярдәм күрсәтергә вәгъдә итә. Республиканец зур дәрт, куаныч белән, юлбашчыбызның Казанда торган елларын, беренче революцион адымнарын җанландырып, яңа буын күз алдына бастыру эшенә бирелә. Музейда яңадан-яңа экспонатлар, документлар барлыкка килә. Ләкин бу әле аз, бик аз. Ульяновлар гаиләсе торган йортны нәкъ 1884 елгы хәлгә китерү, шул вакытларгача җиһазлау сорала. Ә вакыт аз. Октябрьнең егерме еллыгына өлгертергә кирәк. Шул көнне музейның ишекләре ачылырга тиеш! Гений көне-төне йөгерә, эзли, ашыга.

1937 елның җәй уртасында Республиканец Мәскәүдән, Крупскаядан телеграмма ала. «Музей оештыру эшләре буенча тиз арада миңа килүегезне үтенәм. Н.Крупская». Гений шул көнне үк вокзалга йөгерә – билет алып, вагонга кереп утыра. Поезд кузгалыр алдыннан гына купега НКВД вәкиле кереп, Республиканецны «бер генә минутка» комендатурага кереп чыгарга чакыра.

Менә шулай итеп, 1937 елда аны кулга алалар. Ул төрмәдә утырган вакытта аларның Рафаэль исемле уллары туа. Гений Республиканецны кулга алганда, Зифа апаның үзен дә кулга алырга тиеш булалар, әмма аның йөкле булуын күрәләр. Театрда усал җыелышлар үткәрелә, Зифа апа шунда чыгыш ясап, баласы хакына, рәсми рәвештә иреннән баш тартырга мәҗбүр була. Ә ире Гений Республиканец Казан мәйданнарына куелган репродукторлардан Зифаның җырлавы яңгыраган вакытларда, тәрәзәгә капланып һәм өзгәләнеп, хатынының моңлануын тыңлый торган була. Төрмә камерасында җәзаларга түзә алмыйча, Гений Республиканец акылдан шаша, 1943 елда аны төрмәдән психбольницага җибәрәләр. Ул шунда вафат була.

Бу – аянычлы гына түгел, куркыныч, коточкыч язмышлар... Бу вакыйгалар Зифа апаның тавышында, язмаларында, җырларында чагыла.

Зифа Басыйрованың ире Гений Республиканец һәм Зифа апаның язмышы Ибраһим Сәлаховның «Колыма хикәяләре» әсәрендә яктыртыла. Гений Республиканец белән бер камерада утырган Ибраһим Сәлахов, ирекккә чыкканнан соң, Зифа Басыйрова белән очраштыра. Җырчы иреннән рәсми төстә баш тартырга мәҗбүр булса да, күңеле һәм йөрәге белән аны ташламаган икәне аңлашыла.

Ибраһим ага үз китабында Зифа апа белән очрашу минутларын болай искә ала:

«1957 елны, реабилитациядән соң, мин Казанда Республиканецның хатыны, атаклы җырчы Зифа Басыйрова белән очраштым. Гений Измайловичның соңгы көннәре турында Зифа ханым миңа менә нәрсәләр сөйләде: «1942 елның көзендә мине Эчке эшләр халык комиссариатына чакырдылар. Котым очты. Нишлисең, бардым. Җаным уч төбендә. Мине чакырган кеше, ишектән керүгә, исәнләшеп-нитеп торма-

аның аяныч язмышлы ире

ды, бик коры гына: «Сез Гений Измайлович Республиканецны беләсезме?» – диде. «Ничек белмәскә, ул – минем ирем. Ул кайда, 5 ел аның турында бернәрсә дә белмим», – дидем. «Ярый, хәзер күрешерсез», – диде. Өнемме? Төшемме? Аптырап калдым. Мине, машинага утыртып, Арча кырындагы психбольницага алып килделәр. Бер палатаның ишеген ачып, эчкә керергә куштылар. Янымдагы кешеләр белән бергә кердем. Бер генә карават. Анда баштанаяк одеялга уранган бер кеше ята. Врач килеп одеялны ачты:

– Гений, торыгыз, хатыныгыз килде.

Караваттагы кеше тиз генә одеялын тартып алып тагын уранды.

– Торыгыз!

– Комачауламагыз, зинһар, мин Владимир Ильич белән сөйләшәм...

Тавыш таныш, Гений тавышы... Йөгереп барып одеялны тартып алып кочакламакчы идем, ул мине этеп җибәрде. Егылдым. Мин аягүрә басканда, алдымда коточкыч бер кеше басып тора иде, бөтен йөзен кара сакал баскан. Күзләре, акаеп, әле – бер, әле икенче якка ташлана.

– Кем сез? Нигә рөхсәтсез кердегез?! Әйттем бит, мин Ильич белән сөйләшәм. Китегез! Китегез!

Ул безне куып чыгарды. Мин аннан соң бу палатага берничә тапкыр килдем. Ләкин ул: «Ильич белән сөйләшәм, вакытым юк», – дип, палатага керттермәде. Берничә елдан соң мин аның үлүе турында хәбәр ишеттем»...

Моннан тыш, Зифа Басыйрова Хәсән Туфанның кодагые да. Зифа апа театрда Хәсән Туфанның хатыны Луиза Сәлиәскәрова белән дуслаша, икесен дә уртак кайгы берләштерә...

Мемориаль тактаның авторы – Зөлфия Мөхәммәтҗанова. Ул Зифа Басыйрованың җырларын тыңлап илһамланганы турында сөйләде. Мемориаль такта – ике як урамга карап торган итеп урнаштырылган.

– Кызыклы иҗади проектларны тормышка ашырырга ярдәм иткәне өчен Мәдәният министрлыгына, филармониягә рәхмәт. Истәлек тактасын ясаганда Зифа Басыйрованың җырларын тыңладым. Шулчак балачагым искә төште. Шуңа күрә барысы да уңышлы килеп чыкты, дип уйлыйм, – ди автор.

Мемориал такта ачу тантанасында «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев, Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире, Тукай премиясе лауреаты, шагыйрь Ләбиб Лерон, Татар дәүләт филармониясе директоры Кадим Нуруллин, Камал театры музее мөдире, Татарстанның халык артисты Луара Шакирҗанова, Мөслим районы җирлеге башлыгы урынбасары Азат Әхмәтҗанов, юрист Флюр Баһавутдинов һ.б. чыгыш ясады.

Сөембикә КАШАПОВА,
Зилә МӨБӘРӘКШИНА.
Салават Камалетдинов фотолары.

Мәдәни җомга
27 октябрь
№42, 2023

МИН – «КУЛАК»

Мин – кулак туруны, ягъни оныкчыгы. Бөек Ватан сугышы елларында дәү әнинең әтисе Суфиян бабайны, «кулак» дип атап, Минзәлә төрмәсенә алып китәләр. Исем-фамилиясеннән кала берниндИ хәтер юк бабай турында. «Кулак баласы» булган дәү әниемнән генә ач һәм ялангач еллар корыч кебек хатын ясаган.

30 октябрь – сталинизм елларында сәяси репрессияләрдә һәлак булган һәм зыян күргән кешеләрне искә алу көне. Кызганыч, бу көнгә күпмедер күләмдә минем дә катышым бар. Мин – «кулак» оныкчыгы. Ул чорда җитеш яшәүчеләрне – «кулакларны» – гаиләләре белән бергә сөргәннәр. Бригадир булып эшләп йөргән Фәсхиев Суфиян бабайны үзен генә алып китеп, төрмәдә башына җитәләр. Бәлки, аның «халык дошманы» дигән «махсус» исеме дә булгандыр.

Минзәлә төрмәсендә һәлак булган Суфиян бабай турында берниндИ мәгълүмат та юк. Бары тере хәтер – әтисен алып киткәндә 2 яшьтә булган, Актаныш районы Такталачык авылында яшәүче дәү әнием – Габдуллина Зәнфирә Суфиян кызы гына бар. Аңа да хәзер 83 яшь инде.

«Кечкенәрәк чакта «кулак», «халык дошманы» дигән сүзнең мәгънәсен аңламый идем. «Җиңү парадында нигә син дә чыгып утырмыйсың? Син дә сугыш чоры баласы бит», – дигәч, «Минем әткәй кулак булган бит. Мин сугышчы баласы түгел», – дия торган иде.

Шул «сугышчы түгел», ә «кулак – халык дошманы» баласы булуы аркасында бөтен нәрсәдән мәхрүм булып, интегеп үскән алар. Кешегә акканы «кулак» балаларына таммаган да. Бары хәерчелек, ачлык, авыр эш.

«Сугыш чоры баласы булсам да, мин алар рәтенә кермим. Әткәйне «халык дошманы» дип алып китеп үтергәннәр. Мин 2 яшьтә генә булганмын ул вакытта. «Сугыш чыгарга берничә ай кала, кышка кергәндә алып киттеләр», – дип сөйли иде әнкәй. Әткәй бригадир булып йөргән. Эштән кайтканда көтеп алганнар да өйгә ияреп килгәннәр.

Әткәйне Минзәлә төрмәсенә алып киткәннәр, аннан бер хаты килгән. Күршедә Фазыл дигән бабай бар иде. «Фазыл абыйны җибәрегез, югыйсә мин ачка үләм», – дип язган булган.

Булган ризыкларны төяп, ипиләр, бәрәңгеләр салып, Фазыл абыйны әткәй янына җибәргәннәр. Минзәләгә хәтле җәяү барган. Ул барганда әткәйне күреп, сөйләшеп, әйберләрен тапшырып кайткан. Ул ризыкларны үзе ашый алды микән әткәй, юк микән? Минзәлә төрмәсе элек бик әшәке, бөтен тирә-якка данлыклы төрмә булган бит.

Берәр айдан соң әткәй: «Булдыра алсаң, Фазыл абыйны тагын җибәр», – дип язган. Фазыл абый тагын барган. Икенче баруында әткәй булмаган инде. «Юк бит инде ул», – дигәннәр. Үлгәнен дә, нишләткәннәрен дә әйтмәгәннәр. Атканнардыр, дип уйлыйм мин аны. «Халык дошманнарын» атканнар бит инде ул чакта. Атып үтергәннәрдер инде...

Әнкәй аны, нык, тап-таза, «дастыйн», ныклы багана кебек кеше иде, дип сөйли иде. «Атканнардыр, тиз генә үлә торган кеше түгел иде ул», – ди торган иде. Бернәрсә дә бирмәсәләр, ачтан да үлгәндер бит әле. Әнкәй эчтә елый, без тышта елыйбыз... Түләмәсәң, шулай җәза бирәләр иде. Шуңа әнкәй, куркып, бөтен әйберләрне сатып бетереп түләде ул бурычларны. И юаш иде әнкәй дә...

Кешесе дә әшәке булган инде. «Нимес» түгел бит алар, үзебезнең район кешеләре. «Нәчәлство», милициясе дә булгандыр. «Уполномоченный» дип йөртә торганнар иде ул кешеләрне. Тегеннән килеп чыккан «нимесләр» булсалар бер хәл, үзебезнең ил кешеләре бит. И, кабәхәт булган алары да…»

1947 елны дәү әни укырга керә. Сугыштан соңгы илкүләм ач, ялангач еллар. Өйләре мәктәп янында гына була аларның. Озын тәнәфес саен иптәш кызлары өйләренә кайтып килә. Ул да буш өенә йөгереп чыга торган була.

«Озын тәнәфес» дигән булып, кызлар кайтып китә, мин дә чыккан була идем. «Бөкрәеп йөгереп чыга бу бала», – дип, күрше Тәгъзимә әби көн дә инде... «Үлгән» дигән кәгазе килде, дип әйтмәде әнкәй. Мин бәләкәй булып онытсам да, андый кәгазьне саклар иде. Паспорт ишесе дә, «кулак», «халык дошманы» дигәне дә, «үлгән» дигәне дә – берниндИ кәгазь дә юк бит. Югалгандыр инде...

Әти белән бергә өйдәге бөтен әйберне алып чыгып киткәннәр. Шикәрләрне, оннарны, атларны, сыерларны… «Өч атыбыз бар иде», – дип сөйли иде әнкәй. Өчесен дә алганнар, ике сыерның берсен генә калдырганнар. Шул сыер алып калды инде безне үтермичә.

Кырып-себереп, булган бөтен әйберне алып киткәннәр бит. Безнең өйдә башка бәйләргә яулык та калмаган. Әйберләрне алып киткәндә күрше әби, кызларын иярткән кереп, башларына безнең яулыкларны бәйләткән. Аларын алмасыннар өчен шулай иткән. Безнең әни шуны да бәйләтә белмәгән. Ә әбекәй яхшы кашемир яулыкларны гомер буе җыйган да җыйган.

Әйберләргә тигәч, әткәйне алып киткәч, әбекәй алмашынган, хыялланган. Әткәй киткәч, ул 3 еллап кына торып калган. Әбекәйне бик хәтерләмим дә. Өй алдыннан кергәннәре, чыкканнары, самавыр күтәреп йөргәннәре генә истә сыман.

Башлары чигүле тастымалларны шул ук көнне алып китә алмаганнардыр инде. Әбекәй аларны базга туфракка күмеп куйган. Күпмесендер ул кешеләр киткәч алып чыккан, калганын онытты микән инде. Без ул өйне сатып сүткәндә килеп чыкты шул әйберләр. Икенче көнне авылдагы базарда безнең киемнәрне чыгарып сатканнар. Очсыз гына бәягә алган кешеләр. Ул акчаны кая куйганнардыр...

Әбекәй 30 сумлык акчаларны да өйнең түбәсенә, такталар арасына яшереп куйган булган. Акча яшергәнен әнкәйгә дә, беркемгә дә әйтмәгән. 3 тиен, 5 тиен дә түгел, кызыл 30 сумлыклар иде ул. 1947 елны акча алмашынды, 1948 елны без өйне алмаштык. Икенче урынга күчереп салырга дип, безнең зур өйне сүткәндә, шул акчалар килеп чыкты. «Их» та «аh» килдек. Өй түбәләренә менеп уйный идек кызлар белән. Кем «анда акча күмелгән» дип, туфраксасын актарган инде?.. Кирпеч сыман тимер сандык туп-тулы акча булган. Эх, бер елга иртәрәк алышкан булсак», – дип сөйли дәү әни.

Зур өйләрен 500 сум акча, 5 пот бәрәңгегә кечкенә генә, черек, эче агартылган өйгә алмашалар. «Агарткач, матурдыр әле», – диештек. Чиста итеп агартылган, бәләкәй генә өй иде ул».

«Кулак гаиләсе» исеме алар артыннан кара шәүләдәй ияреп йөри. Башкалардан арттырып, бурычка керә-керә, налог түлиләр.

«Бакчага бәрәңге утырта идек тә, әткәй «халык дошманы» булгач, җидешәр центнер бәрәңгене алып чыгып китәләр иде. Үзебезгә утыртырга бәрәңге дә калмый. Кешеләргә бакча казышып, бәрәңге утырта идек.

Безгә 40 кило ит «нәрәте» түләтәләр иде. Бер елны 10 каз баласы үстердек. Шуның 8 ен, 4 әрләп 2 каз оясына салып, әнкәй белән Чөгәнә дигән авылга илттек. Ит җыя торган җир Чөгәнәдә иде. Авыл советына күрсәтегез, дип, «тапшырды» дигән квитанция биреп җибәрделәр.

Сыер бар чагында 200 шәр литр сөт тапшырталар иде. Сауган саен илтеп бирә идек. Аның хәзерге сыман сөте дә күп булмый иде бит. Ул сөтләр, итләр фронтка киткәнмени? Район убырлары ашап яткандыр инде! Фронтта безнең беркем дә булмаса да, «халык дошманы гаиләсе» дигән булып, күп интектерделәр.

Әнкәйне бер юлы авыл советына чакырдылар. Совет та бер байның өендә иде. Аларны да куып чыгарып, ул өйне «сәвит» иткәннәр. Бик биек, алты почмаклы өй иде ул «авыл советы» дигән җир.

Әнкәй төнлә белән генә басудан эштән кайтты, налог түләмичә калган булган. Без Фагыйлә апа белән тышкы якта калдык, әнкәйне бикләделәр дә киттеләр. Әнкәй эчке якта, без тышкы якта килеш кундык шулай. Әнкәйне җәлләп, чыгарырлар, дип утырдык. И тапый черки, үзебезнең корсак ачты, үзебез куркабыз, бәләкәйләр диярлек бер бәрәңге бирә торган иде. Өй җылытырга салам ягалар да, шул салам көлендә бәрәңге пешерәләр иде.

Без, ягарга дип, кура җыя, сыер тизәкләрен катыра идек. Аш кайнатырга да, бәрәңге пешерергә дә, чәй кайнатырга бер казан иде. Яшәргә кирәк бит ничек тә».

Дәү әнинең хәзер дә иң яраткан ризыгы – бәрәңге. Ярып пешергән бәрәңге һәм ипекәй булсын аңа. Әллә ниндИ затлы әйберләр пешерсәң дә, яңадан килеп, бәрәңге пешереп ашый. «Кеше бакчаларыннан черегән бәрәңге эзләп, шуларны пешереп ашый идек», – дип сөйли. Ипи кисәген ашап бетермичә, яки катырып калдырганны күрсә, әрәм итмәскә куша. «Өстәлдә ипекәй булып торсын, исраф итмәгез», – ди. Балачакта күргәннәре 80 нең теге ягына чыгып, мул тормышта, мул өстәл артында утырганда да онытылмый аның.

Ипи турында сөйләшә башласак, дәү әни һәрвакыт бер тарихны сөйли. Ул тарихны әллә ничә тапкыр ишеткән булсам да, һәрвакыт йөрәгемне чеметеп ала.

«Мин бәләкәй идем әле ул чакта, шул сугыш еллары булгандыр. Бәләкәй булсам да, урлашкан истә калган. Корсак ачкан, кая барырга да белеп булмый. Урам буйлап бардым да бардым. Бер әбиләрнең өенә кердем, өйдә беркем дә юк. Өстәлләрендә ипи тора.

ОНЫКЧЫГЫ



Шул бер ипи кисәгән алдым да чыгып йөгердем. Алар яшәгән тыкрыкны чыккач, яртысын утырып ашадым. Яртысын кая куярга белмим. Өйгә алып кайтсам, әнкәй әрли, каян алдың, дип. Шул ярты кисәк ипине җиргә кычыткан арасына күмеп куйдым. Яңадан корсак ачкач барган идем, юк теге ипекәй. Эт-мазар алып киткәндер инде...

Без 1952 елларны гына әзрәк ашау күрә башладык.

Әтисез үскәнемә сәбәпче булган Сталин режимы, комсомолга керү хыялы белән янып йөргән елларын ул хәзер көлеп искә ала.

«1953 елны Сталин үлде, мин 6 нчыда укый идем ул чакта. Мәктәпнең бөтен җиренә кара әләмнәр элдерделәр, бөтенебез дә елыйбыз. Кайгы уртаклашырга дип, пионер клубына кертеп тутырдылар. Сталинның кем икәнен белмибез, кеше елаганга кушылып елыйбыз.

Җиңү бәйрәмендә мәктәптә, чөгендер турап, ашлар пешерәләр, имеш, сыйлыйлар иде. Шул ашларны ашап, демонстрациягә чыга торган идек. Яланаяк, – диде дә, минем яланаякка карап куйды дәү әни. – Аягыңа киеп йөре. Гомер буе яланаяк йөргәнгә авырта бу аяклар. Сезнең кияргә киемегез бик күп бит», – диде.

«И, алсалар гына ярар иде» дип борчылып, Актанышның үзенә комсомолга керергә төшә кызлар. Аякта – чабата, өстә – детдомнан «списать» ителгән малайлар пәлтәсе була.

«Үземчә әйбәт укыйм, «өчле»ләрне дә сирәк ала идем. Күршедәге әби: «Кызым, сиңа укытучы булырга кирәк. Кулларың да туры килеп тора бит», – дия торган иде. Укып булмады шул укытучы булырга. Аның өчен акча кирәк. Безнең тамак туйдырырлык та акча юк иде.

Әле мәктәптә укыганда ук Шәргия исемле апага мәктәп идәне юа торган идем. Ул миңа чәй тәлинкәсе хәтле генә бер бәләкәй ипи биреп чыгара. Аны йөгерә-йөгерә күтәреп алып чыгам да, өчебезгә бүләм. Әнкәй: «И бәбекәем, үзең аша инде», – дия-дия мине кыстый иде.

7 нче классны бетергәннән соң амбарга йөрдем. Аннан кесәгә салып булса да ярма алып кайтып, ярма ташында яра идек. Тотсалар, беттең. Зөләйха дигән әби бар иде. Алар оекны бот арасына бәйлиләр дә тутырып кайталар. «Синең бер нәрсәң дә юкмыни соң?» – дип әрли иде. Мин, бала-чага, аларын белмәгәнмен инде. Кесәләргә салып кайткан була идем. Аннары, кешеләр таралышкач, амбарның икенче ягына 1-2 кило ярманы янчыкка салып куеп, караңгы төшкәч алып кайттык. Берәрсе күрсә, баш бетәсе иде.

Менә шулар бөтенесе дә күз алдына килә. Онытылмый инде ул, балакаем. Әнкәй дә интекте, без дә интегеп кенә үстек. Үсеп, үзебез урлаша башлагач кына авызга ризык керде безнең...»

Дәү әни минем өчен гомергә ныклы һәм усал хатын булды. Бөтенесен үзе эшләде, үзе контрольдә тотты. Яхшы тормыштан шундый корычка әйләнмәгән инде ул да. 17 яшьлек чагында торф та ташый, кул пычкысы белән урман да кисәргә туры килә аңа.

«Киров өлкәсе Нократ Аланы районына торфка бардык. Анда акчасы да әйбәт, авылдагыча түгел. Өскә күлмәкләр, аякка елтыравыклы итекләр, әнкәйгә дә, Фагыйлә апага да күлмәклек ситсылар алдым шул торф акчасына.

Кич белән безгә борчаклы аш ашаталар иде. Шул борчаклы ашны 2 порция алып кайта идем. Ипи алсам, акча күп китә. Ә аш белән эч тула, тамак та туйган кебек була иде. Ипине көндез басуда эшләргә генә ала идем. Анысы да бер телем генә булгандыр инде».

Киләсе елны мәктәпкә җыештыручы булып эшкә керә. Шул ук елны, яңа мәктәп салырга агачка дип, Әгерҗе ягындагы урманга җибәрәләр.

«Урманга барып, кул пычкысы белән агач кистек, арба белән Идел ярына чыгара тордык. Ул агачны аннары укытучылар бүлешеп алып бетерде. Берсе өй салды, берсе келәт. Безгә бер генә агач та бирмәделәр.

Хәзерге акылым булса, талап алган булыр идем. Үзем дә юаш булдым, әнкәй дә юаш иде.

Фагыйлә апа чучка фермасына чучка карарга керде. Бер-ике капчык икмәк бирәләр иде колхозчыларга. И аның да барасы килми иде фермага. «Куркам» ди торган иде. Чучкалар усал, эре иде ул чакта. Эшләгәч, колхоз 20 тиен хезмәт хакын да бирә башлады. Ел буе җыйгач, хәтәр генә була торган иде.

Бер елны болында печән эшләделәр. Печән җыеп, чүмәлә салып йөргәч, Фагыйлә апага бер кибән печән биргәннәр. Безнең ул чакта сыер юк, аны алдагы елны гына саткан идек. И, сатмаган булсак, диештек. Шул печән әзерли алмаганга саткан идек анысын да. Ул, кибәнне сатып, үзенә киемнәр, әйберләр алды. Миңа да өлеш чыкты. Шул бер кибән печәнне саткач та тормышлар бераз рәтләнеп китте.

1960 елны мин бабаңа кияүгә килдем. Ул елны Фагыйлә апа икмәкне күп итеп алды. Өй алдындагы сәкене тартма кебек итеп ясап, бодайларны шунда бушаттык. Никах ашына чыккач, кайнанам күргән ул бодайны. «Кеше «хәерче» дип әйтә, өй аллары тулы икмәк, нигә хәерче булсыннар алар», – дип кайткан».

Кияүгә чыгып, 3 ир бала алып кайта дәү әнием. Төпчек улы Алмаз – минем әтием. Төп йортта дәү әни белән үскән бала мин. Мул тормышта, мул өстәл артында утырганда да, ул ирексездән «әрәм итмә, исраф итмә» дип әйтеп куя. Безнең буын ул сүзләрне аңлап та бетерми, аңларга язмасын да.

Кечкенәдән сөйләгән «кулак кызы бит мин» дигән сүзләрнең мәгънәсенә соңгы елларда гына ныклап төшенә башладым. Сугыш чоры ачлыгы, ялангачлыгында үскән балалар шул «кулак – халык дошманы баласы» дигән сүз аркасында тормышның ачысын башкаларга караганда ныграк та татый. Әтиләре сугышта үлеп калган балалардан бер башка түбән булып үсәләр.

«Сугышта катнашкан кешеләрнең балаларына 40 ар сум пенсия бирделәр. Безгә ул да юк. Ул пенсияне алгач, кызлар кайсы яулык, кайсы күлмәк, кайсы галош алып кия торган иде. Әтинең кулак булганына без дә бөтен нәрсәдән мәхрүм булдык.

«Әмирҗан бабайлар, Рәгыйләләрнең әтиләре сугыштан кайткан», – дип сөйлиләр иде. «Кешеләрнең ирләре кайта», – дип сыкрана торган иде әнкәй. Безнең беркем дә кайтмады. Әтинең абыйсы да сугышта үлеп калды. Төрле яклап бәхетсез булып үстек... «Күрмәгәннәр калмады, күрмәдем бер Аллаһы» – минем тормыш шул инде.

Әнҗе ГАБДУЛЛИНА.

Россия бүләкләре

Татарстанның ун музыка мәктәбе педагогы 2023 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлары өчен бүләккә ия булачак. Россия Мәдәният министрлыгы сайтында чыккан җиңүчеләр исемлегендә түбәндәге мөгаллимнәр бар: Ринат Мөхетдинов (Казанның Киров районы 13 нче балалар музыка мәктәбе), Эльвира Галиуллина (Казанның 5 нче балалар музыка мәктәбе), Фәридә Әпсәләмова (Казанның Фёдор Шаляпин исемендәге балалар музыка мәктәбе), Фәридә Кәлимуллина (Казанның Мәскәү районы Илһам Шакиров исемендәге 32 нче татар балалар музыка мәктәбе), Елена Шакирова һәм Альбина Маликова (Казанның Совет районы 4 нче балалар сәнгать мәктәбе), Лариса Звонарева һәм Вероника Михайлова (Казанның Киров районы 24 нче балалар музыка мәктәбе), Эльвира Ногманова (Казанның Рөстәм Яхин исемендәге 3 нче балалар музыка мәктәбе) һәм Елена Лобанова (Чаллының Салих Сәйдәшев исемендәге 6 нчы балалар музыка мәктәбе).

«Конкурс нигезендә икенче тапкыр иң яхшы педагогларны билгеләп үтәбез һәм аларга бүләкләр тапшырабыз, – дип хәбәр итәләр министрлыкның сайтында. – Балалар сәнгать мәктәбе укытучыларына – 500 меңәр сум күләмендә 100 премия, педагогика училищелары һәм югары уку йортларының мөгаллимнәренә 1 млн сумнан 100 премия каралган».

Быел конкурста катнашырга 565 кеше теләк белдергән: югары уку йортыннан – 71, училищелардан – 106 һәм балалар сәнгать мәктәпләреннән 388 мөгаллим. Илнең 50 дән артык төбәк вәкилләре лауреат булган.

Россия Мәдәният министрлыгы тарафыннан оештырылган махсус комиссия кандидатларны өч кагыйдә буенча бәяләгән: белем бирүгә авторлык методларын кертү, укучыларны укыту нәтиҗәләре, иҗади чаралрда башкаручы сыйфатында катнашу тәҗрибәсе.

Премияләр 2022 елда Россия Президенты Владимир Путин карары белән булдырылган.

Хатынь җәллады

Григорий Васюра – Гитлер оккупантларына ярдәм иткән өчен атып үтерелгән соңгы хаин. Кимендә 360 кешенең гомерен шәхсән үзе өзүгә карамастан, аны 1986 елда гына кулга алганнар. Васюра үз исем-фамилиясе белән гомере буе тыныч кына яшәп яткан, хәтта совхозда завхоз булып та эшләгән. Картлыгында ничек фаш иткәннәр соң бу явызны?

Григорий Васюра Киев губернасының Чигирин шәһәрендә туган, мәктәпне тәмамлагач, педучилищеда укыган, укытучы булып эшләгән, 1936 елда исә Киев хәрби элемтә мәктәбендә укып, лейтенант булган, 67 нче укчы дивизиягә җибәрелгән. 1940 елның октябрендә Латвиягә күчергәннәр, шунда өйләнгән. Сугыш башланганда, өлкән лейтенант Васюра 83 нче саперлар батальонында элемтә башлыгы булган, 28 июньдә Лиепаяда әсирлеккә төшкән.

Концлагерьда немецлар белән хезмәттәшлеккә ризалашкан, 1942 елның февралендә Вустрау лагерена пропагандистлар курсына җибәрелгән, октябрьдә инде аны Украинадагы 118 нче шуцманшафт батальонына башта взвод командиры итеп куйганнар, тиз арада штаб башлыгына әйләнгән. Батальон командиры булып немец Эрих Кёрнер саналса да, аның белән чынлыкта Константин Смовский белән Григорий Васюра җитәкчелек иткән.

Декабрьдә хаиннар батальонын Белоруссиягә җибәргәннәр. Алар Логойск районы Плещеницы бистәсендә урнашкан һәм партизаннарга каршы көрәшкән. Инде 1943 елның 6 гыйнварында ук батальон Чмелевичи авылында партизаннарга ярдәм иткән өч кешене үтергән, хатын-кызлар һәм балаларны, чишендереп, урамга куып чыгарган һәм берничә сәгать суыкта тоткан, йорт-каралтыларын талаган һәм 58 йортны яндырган.

Әммә, сатлыкҗаннар никадәр генә явызларча кыланса да, партизаннар хәрәкәте дә тынмый, һаман активлаша. 1943 елның 2 мартында Логойскига украин полицайларына ярдәмгә Оскар Дирлевангерның җинаятьчеләрдән тупланган СС бригадасы килә. 22 мартта шуцманшафтның 118 нче батальоны һәм Дирлевангер башкисәрләре бөтен дөньяны тетрәткән вәхшилек кыла. Партизаннар рота командиры Ганс-Отто Вельке (ядрә ыргыту буенча Олимпия чемпионы, Өченче Рейхта популяр кеше) утырган машинага һөҗүм итеп, андагыларның барысын да атып үтерә. Смовский белән Васюра бөтен батальонны күтәрә һәм, юлларында очраган 50 урман кисүченең 26 сын үтергәч, якындагы Хатынь авылына юнәлә.

Өлкән лейтенант Соколов җитәкчелегендәге «Дядя Вася» партизаннар отряды чыннан да бу вакытта авылда була. 118 нче батальонның – 160, Дирлевангерныкыннан 100 башкисәрнең авылны камавына карамастан, өч кешеләре үлеп һәм дүртесе яраланып булса да, отряд камалыштан чыга ала. Тагын да явызланган шуцманнар һәм эсэсчылар авыл халкын Иосиф Каминский сараена куып кертә, бикли һәм ут төртә.

Взвод командиры Василий Мелешко сугыштан соңгы сорау алу вакытында болай искә ала: «Сарайга утны штаб тәрҗемәчесе Лукович төртте. Бикләнгән халык бик каты кычкыра, елый, илерә башлады, хәтта тыңларга да куркыныч иде. Сарай ишеген җимереп ачтылар, ут капкан кеше йөгереп чыкты. Шул чакта Кёрнер сарайга төбәп ут ачарга боерды. Полицайлар мылтыкларыннан ата башлады, ике якка куелган пулеметтан да аттылар. Шәхсән мин үзем атмадым. Бер гаепсез, коралсыз халыкка ата алмадым. Сарайга куып кертелгән йөздән артык хатын-кыз, карт-коры һәм балаларның барысы да янып үлде йә атып үтерелде».

Җәзалаучылар хатирәләреннән күренгәнчә, Васюра атарга әмер бирә һәм сарайдан йөгереп чыккан ут капкан кешеләргә төбәп шәхсән үзе дә ата. Иван Петричук күрсәтмәләрендә мондый юллар бар: «Минем сакта торган урыным сарайдан 50 метрларда иде. Алты яшьләрдәге малайның ут эченнән йөгереп чыкканын якыннан күрдем. Шундук аңа пуля тиде. Офицерлардан берсе атты – йә Кёрнер, йә Васюра. Сарайда күпме сабый булуын белмим. Без авылдан киткәндә, ул инде янып беткән, эчендә тере кеше калмаган, кара күмергә әйләнгән зур һәм кечкенә мәетләр генә төтенләп ята иде...»

Авылның нибары сигез кешесе исән кала. Барлыгы 149 кеше, бөтен йорт-җир юк ителә. Хатынь – украин җәзачылары һәм эсэсчыларның тәүге тәҗрибәсе, шуннан соң башкисәрләр белорус авылларын халкы белән бергә даими яндыра башлый. Васюра 13 майда Дальковичи авылы өчен партизаннарга каршы сугышта батальон белән җитәкчелек итә һәм аны яндырырга боера. 27 майда батальон Осови авылында 78 кешене атып үтерә. Аннары Новая Вилейка халкын мина кырына куып чыгарып үтереп бетерә. Тагын берничә көннән соң Васюра Старая Вилейка авылында ике амбарда 17 бала, 7 хатын-кыз һәм 6 ир-атны яндырырга әмер бирә. 118 нче батальон Васюра кушуы буенча Маковье һәм Уборок авылларын да, яндырып, җир белән тигезли, бер кеше дә исән калмый. Каминская Слобода авылында 50 яһүд атып үтерелә.



● **Григорий Васюра судта.**

«Багратион» һөҗүм операциясе башлангач, Белоруссиядән качкан полицайларны Франциягә күчерәләр. Бер атнадан соң ук исә, 1944 елның 27 августында, алар тулы составта диярлек французларның каршылык хәрәкәте ягына чыга һәм Тарас Шевченко исемендәге 2 нче украин батальонына әйләнә. Сугыш тәмамлангач, аларның күбесе чит илләрдә торып та кала – кемдер Канадага, кемдер АКШка, кайсылары исә Латин Америкасына китеп урнаша. Васюра исә кайтырга була – Латвиядә аны хатыны белән кызы көтә.

СССРга кайткач, фильтрлау лагеренда ул үзенең Белоруссиядә кылган вәхшилекләрен яшереп кала, француз партизаннары ягында сугышуын исә күпертеп күрсәтә. Шулай булса да, 1952 елда сатлыкҗанлыгы өчен 25 елга лагерьга хөкем ителә. Әммә 1955 елда ук Хрущёв амнистиясе буенча ирекккә чыга һәм Украинаның Киев өлкәсендәге Великая Дымерка

Григорий Васюра

● 102 нче, 115 нче һәм 118 нче батальоннар старшиналары Минскидагы хәрби курсларда, 1942 ел.

авылында хәтта үз исемен яшермичә дә яши, зур совхозда директорның хуҗалык эшләре буенча урынбасары була. Рәхимсезлеге монда да күренә, ул үз кул астында эшләүчеләрне еш кыйный торган була. Совхозда аннан бөтенесе дә курка. Шулай да аны 1984 елда «Хезмәт ветераны» медале белән бүләклиләр, Киев хәрби училищесының мактаулы курсанты итәләр, хәтта мәктәпләргә ветераннар белән очрашуларга да чакыралар.

118 нче батальонның берничә полицае фаш ителә һәм атып үтерелә. Аларның күрсәтмәләрендә Григорий Васюра исеме дә була. Әмма аны беркем дә фаш итә алмый яки моны эшләргә теләми. Ул үзен-үзе фаш итә. 1985 елда М.Горбачев Җиңүнең 40 еллыгы уңаеннан бөтен исән ветераннарга орден бирергә карар кыла. Васюраның да әлеге орденны аласы килә, һәм ул шул бүләкне дәгъвалап военкоматка килә. Документларда актарына башлагач, аның хәбәрсез югалганнар исемлегендә булуы ачыклана. 1975 елда атып үтерелгән хаин Василий Мелешко күрсәтмәләренә юлыгалар. Тикшерү 26 шаһитның (118 нче батальон полицайларының һәм Хатынь фаҗигасендә исән калучыларның) күрсәтмәләрен туплый. Суд эше 14 том тәшкил итә, тикшерүчеләр 1943 елның 22 мартындагы вакыйгалар хронологиясен минутларга кадәр төгәллек белән торгызуга ирешә.

Васюра бик озак үз гаебен танымый, акланмакчы була, шаһитларның күрсәтмәләре белән стенага китереп терәгәч кенә, куралмавын яшермичә, йөрәкләнеп: «Әйе, сезнең Хатыньны мин яндырдым!» – дип кычкыра. 1986 елның 26 декабрендә Белоруссия хәрби округы трибуналы Григорий Васюраны атарга хөкем чыгара. Суд аның кимендә 360 кешенең үлемендә шәхсән гаепле булуын дәлилли. Шуңа кадәр бөтен СССР халкы Хатынь авылын немецлар яндырган дип ышана.

Совет җитәкчелеге моның украин коллаборантлары вәхшилеге булуы хакында хакыйкать совет Украинасы һәм совет Белоруссиясе халыкларын ызгыштырырга мөмкин, дип саный. Шунлыктан Украина КП ҮК Беренче секретаре Владимир Шербицкий Мәскәүгә махсус мөрәҗәгать юллый һәм Хатынь халкын ерткычларча үтерүдә украин полицайларының катнашуы турында мәгълүматны яшерүне үтенә. Шулай итәргә җыеналар да. Әмма үзгәртеп кору һәм хәбәрдарлык чоры башлангач, әлеге фактны берничек тә яшереп кала алмыйлар.

Васюраны 1987 елның 2 октябрендә атып үтерәләр. Әлеге кеше кыяфәтендәге убырның кабере дә юк.

● Хатыньдагы һәйкәл.

«Две Войны» хәрби-тарихи каналы, Дзен.ру;
Александр ЗВЯГИН,
«Палач Хатыни Григорий Васюра», Проза.ру.
Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА тәрҗемәсе.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

28 октябрь (шимбә). ***Рабигүл ахир аеның 13 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 16.49 сәгатьтә калка, 6.45 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.34 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бигрәк тә бирешүчән.Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Гөлбадран шифасы

30 грамм кипкән гөлбадран чәчәген 100 грамм кайнаган тозлы суда 20 минут төнәтәләр дә, матдәләр алмашын яхшырту өчен, шул төнәтмәдә сөлгене чылатып, бөтен тәнне кызарганчы ышкыйлар. Борынгылар гөлбадранны мускус белән чагыштыра торган булган.

29 октябрь (якшәмбе). ***Рабигүл ахир аеның 14 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 16.59 сәгатьтә калка, 8.18 сәгатьтә бата. 23 сәгать 24 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 9.30 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

Балык мае дәвалый

Тавык күзе (гемералопия) – эңгер-меңгердә күрү сәләте кимү ул. Аннан котылу өчен, даруханәдән 300 грамм балык мае сатып алып, 3 көн рәттән иртән, ашар алдыннан, 100әр грамм эчәргә кирәк. Тавык күзе организмга Е витамины җитмәгәндә килеп чыга.

30 октябрь (дүшәмбе). ***Рабигүл ахир аеның 15 нче көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 17.15 сәгатьтә калка, 9.49 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 9.26 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Сихәтле май

Җәрәхәтләрне тиз төзәтә торган май ясау өчен, 1әр аш кашыгы бал һәм балавызны кайнар сулы савыт өстендәге савытта эретеп, шуңа 2 стрептоцид порошогы кушалар да, әйбәтләп болгатып, суыткычта саклыйлар.

31 октябрь (сишәмбе). ***Рабигүл ахир аеның 16 нчы көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 17.37 сәгатьтә калка, 11.19 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 9.22 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Безләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Бил авыртканда

Ярты килограмм бәрәңгене кабыгы белән пешереп, изәләр, компресс кәгазенә җәеп, билгә куялар. Өстеннән җылы шарф урап, 20 минут тоталар. Берничә көн рәттән дәвалансаң, авырту басыла.

1 ноябрь (чәршәмбе). ***Рабигүл ахир аеның 17 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 18.12 сәгатьтә калка, 12.39 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 9.18 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Кан басымыннан – карбыз

Гипертониядән интегүчеләргә болай дәваланырга була. Карбыз кабыгы һәм орлыкларын яхшылап киптереп, он хәленә җиткәнче төяләр, ай буена көненә 2 тапкыр яртышар чәй кашыгы кабалар. Елына 4-5 тапкыр шулай дәвалану файдалы. Һәр көн иртән ач карынга 1 чәй кашыгы чи тары ярмасы ашау да кан басымын нормальләштерә. Көненә 2 тапкыр 1 стакан кефирга 1 чәй кашыгы төелгән дарчин салып эчү дә булыша.

2 ноябрь (пәнҗешәмбе). ***Рабигүл ахир аеның 18 нче көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 19.04 сәгатьтә калка, 13.41 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 9.13 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, буйсыну, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь.

Кул оеганда

Бер савытка – салкын, икенчесенә кайнар су салалар. Кулларны башта кайнар, аннары салкын суга 30 ар секундка тыгып торалар, 5 тапкыр кабатлыйлар. Аннан соң кулга скипидар мае сөртеп, җылы бияләй кияләр. 5 көн рәттән иртән һәм кичен шулай дәвалаактлар. 10 процедурадан соң кул оюның нәрсә икәне онытылырга тиеш. Кулларны алмаш-тилмәш әле кайнар, әле салкын сулы кран астында тотарга да була.

3 ноябрь (җомга). ***Рабигүл ахир аеның 19 нчы көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 20.12 сәгатьтә калка, 14.32 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 9.09 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

Сыр таякчыклары

200 грамм эремчеккә 1 йомырка, 2 аш кашыгы он, серкә белән сүндерелгән әз генә сода, 100 грамм уылган сыр кушып, камыр басалар, бармак зурлыгындагы таякчыклар ясап, онда әвәлиләр һәм майда кызыдырып алалар.

Бәрәңге

Татарстан журналистлары Мари Иленең Бәрәңге районы татарларының тормышы, һөнәрчеләре, мәктәпләре һәм мәчетләре белән танышып кайтты. Нигә ул «Бәрәңге» дип аталган? Ашый торган бәрәңге алданрак булганмы, Бәрәңге авылымы?

Казаннан – Биектауга, аннары – Әтнә районына. Район чигенә кадәр килеп җиткәч, юллар начарайды. Якынча 20 километр «дыңгыр-дыңгыр» барганнан соң, ниһаять, район үзәгенә – Бәрәңге авылына килеп җиттек. Татарстан кунакларын ачык чырай, гармун көе, мелна (мари коймагы), күмәч, төш (чәкчәк) белән мари, рус, татар кызы һәм «Якташлар» газетасының баш мөхәррире Фәнил Мусин каршы алды.

Алга таба «дыңгыр-дыңгыр» юлны Бәрәңге районының башлыгы Әлфит Ибраев янына тоттык. Ул 2001 елдан бирле район башлыгы булып эшли. Аңа кадәр 20 ел Яңавыл авылы «Яңа тормыш» колхозында хезмәт куя. Хәзер дә үз авылында, бер катлы гади генә, матур гына өйдә яши.

– Безнең районда 13 мең ярым халык яши, шуның 47 проценты – татарлар. Республикабыздагы 17 район арасында Бәрәңге районы – татарларның иң күмәкләшеп яши торган урыны. Бәрәңге районы 1931 елда төзелә. Башта Татар районы дип атала, әмма соңыннан, Сердә инде «Татарский» дигән район булу сәбәпле, Бәрәңгегә үзгәртелә.

Районда 8 мәчет бар. Иң борынгысы – 1829 елда салынган Мазарбаш авылы мәчете. Бу мәчет Арча районы Ташкичү авылындагы «Мәрҗани» мәчете белән бер проект буенча төзелгән. Бу авылдан Дилә һәм Булат Нигъмәтуллиннар, Ришат Фазлыйәхмәтов чыккан.

Безнең район күбрәк авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнә. 7 млрд сумлык азык-төлек җитештерелә. Республикадагы барлык итнең 23 проценты безнеке – 70 мең тонна ит җитештерәбез. Чагыштыру өчен – Татарстандагы Балтач районында 7 мең тонна ит җитештерелә.

13 мәктәп бар, шуларның дүртесе «Модернизация систем школьного образования» программасы буенча төзекләндерелде. Шулай ук «Точка роста» программасы буенча быел 2 мәктәпнең ремонтына 170 млн акча алдык. Иң беренче итеп Куян авылындагы Гайнан Кормаш мәктәбен төзекләндердек. Ул – безнең иң бөек шәхесләребезнең берсе.

Мин Татарстан башлыкларына: «Сез өйдә, каймак эчендә яшисез», – дип әйтәм, ә безгә исән калырга, тормыш итәргә кирәк. Без начар эшли алмыйбыз, начар булсак, безне басып китәләр, бер арбадан төшеп калдың икән, анда яңадан килеп утырып булмый.

Быел бик күп эшләр эшләнелде: 2 мәктәпне төзекләндердек, поликлиниканы эшләп бетердек, 450 млн сум юлларга гына бүлеп бирелде. Юллар бик начар иде, хәзер әзме-күпме йөрерлек. Минем боларны күреп, башка шундый уй килә: «Бу акчалар элегрәк кайда булды икән?» 22 ел эшләп, безнең районга шул кадәр инвестиция килгәнен хәтерләмим...

Башлык белән сөйләшеп, көлешеп алганнан соң, юнәлешне «Безнең тормыш» район газетасы һәм татарлар өчен чыга торган «Якташлар» газетасы редакциясенә алдык. Фәнил Мусин делегация өчен экскурсия оештырды.

– Безнең редакциянең бинасы сугышка кадәр, 1940 елны төзелә. Сизәсездер, һавасы да икенче төрле. Бүгенге көндә редакциядә 8 кеше эшли. «Безнең тормыш» район газетасы 1932 елны чыга башлый. Аның исеме 3 тапкыр үзгәртелә.

Типография хезмәтләре елдан-ел кыйммәтләнә бара. Шулай ук безнең редакциянең почта белән бөтенләй эшләмәвен, ә альтернатив язылу булуын әйтергә кирәк. Әзерләгән газетаны типография бастыра, аннан соң без аларны ялланган машина йөртүче белән барып алабыз һәм авылларга таратабыз. Ә авылларда договор буенча эшләүче почта таратучылар газеталарны укучыларга тапшыра, – дип сөйләде баш мөхәррир.

Фәнил Мусин, аеруча кискен проблема буларак, чыга торган газеталарның ел саен тиражы кимеп баруын һәм татар телен камил белүче хезмәткәрләр булмавын, гомумән, яшьләрнең район редакциясенә эшләргә кайтмавын атады.

Тәрҗемәче булып эшләүче Рауза Хисмәтуллина 35 ел Портянур мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта, пенсиягә чыккач, редакциягә чакыралар. «Мине ялынып чакырдылар, чөнки татар телендә эшли алырлык бер генә кеше дә калмаган. Аеруча Бәрәңге районының үзәгендә татар теле юк. Ба-

районына сәяхәт

лалар әти-әниләренә хәзер «мама» дип эндәшә; Пушкинны беләләр, ә Тукайны – юк; татарча шигырьләрне ятлый да алмыйлар, теләмиләр дә», – дип, бүлеште Рауза апа.

Алга таба без Яңавыл, Портянур, Мазарбаш һәм Куян авылларына кердек. Алар бер-берсенә бик якын урнашкан. Фәнил Мусин авыллар тарихы белән таныштырып барды.

– Риваятьләр буенча, Бәрәңге авылы 1550 елларда барлыкка килгән, бирегә Казан ханлыгыннан качкан татарлар килгән, ә архив документлары буенча 1685 ел күрсәтелә. Башта авылны «Беренгуэ» дип атыйлар, ул фарси телендә «изгеләр авылы» дигәнне аңлата. Менә шуннан кыскартылып калган.

Безнең авылга исем бәрәңгедән бирелмәгән, киресенчә, без бәрәңгегә атаманы биргәнбез, ягъни бәрәңге Россиягә кергәнче үк инде безнең авыл Бәрәңге булган. Ә 1842 елны Мазарбаш авылында яшәүче Фәйзулла Гафтиев дигән кеше Петербургтан бәрәңге алып кайта һәм ничек үстерелүе, нинди ризыклар пешереп булуын халыкка күрсәтә. Шуннан соң аны базарда сата башлыйлар. Башта алып кайтучының фамилиясе буенча «Гафти шалканы» дип йөртәләр, ә якын тирәдәге Арча, Әтнә районнарыннан килүчеләр аны «бәрәңге шалканы» диләр. Аннары «шалканы» төшеп югала да, «бәрәңге» генә кала, – дип сөйләде ул бәрәңге атамасының барлыкка килүе турында.

Яңавыл авылының «Гайнул чишмәсе» янында «Ак калфак» коллективы җырлап каршылады. «Без чишмәбезнең данын еракларга җиткерергә телибез. Элегрәк чишмә янында сугыш ветераны Гайнулла бабайның йорты тора иде. Шуннан чишмәбезгә «Гайнул чишмәсе» дигән атама бирелде. Халкыбыз узган гасырның 70 нче елларына кадәр чишмәбездән су ташыды, әмма су колонкалары куелып, йортларга су кертелгәч, чишмәгә йөрүчеләр кимеде, чишмәбез ташландык хәлгә килде. Быел җәй көне ир-атларыбыз җыелып, чишмәбезне төзекләндерде», – ди алар...

Яңавыл авылыннан ерак түгел Портянур авылы урнашкан. Биредә безне зур заманча ремонт ясалган мәктәп, фельдшер-акушерлык пункты каршы алды. Яңавыл Портянур авылы җирлегенә кергәнгә, башлангыч сыйныфларны Яңавылда укыган балалар укуларын Портянур мәктәбендә дәвам итә.

«Портянур мәктәбендә 70 кә якын бала укый, ә балалар бакчасында 21 бала бар. Мәктәбебезгә 62 млн сумлык ремонт ясалды. Хәзер бөтен кеше русча сөйләшә, балалар да кечкенә чактан ук русчага өйрәнә. Милли мәктәп булганга, татар теле дә укытыла: татар теле һәм әдәбият 1-3 нче, 5-8 нче сыйныфларда 2 шәр сәгать, ә 4, 9 нчы сыйныфларда – 1 әр сәгать. Татар телен менә шулай саклыйбыз!» – ди мәктәп директоры Айрат Хәсәнов.

Мәктәп буенча экскурсия вакытында берничә әйбергә игътибар иттек. Безгә «татар теле укытыла торган» дип тәкъдим ителгән бүлмәдә «русский язык» дип язылган. Кызык! Аннан соң мәктәп китапханәсендә китаплар иске, балаларның игътибарын җәлеп итәрлек китап күрмәдек. Шулай ук Айрат Хәсәнов кадрларның җитмәвен дә билгеләп үтте. Биология, химияне читтән килеп укытуларын, ә яшьләрнең кире мәктәпкә кайтып укытырга теләмәүләрен искәртте.

Балаларны бик иске, 1996 елда чыккан татар теле китаплары белән укыталар икән. Алар инде таушалып беткән. Укытучылар бу проблеманы Бөтендөнья татар конгрессына җиткерде. Бу мәсьәлә хәл ителер дигән өметтә калабыз.

Мәктәптән 15 адым ераклыкта медпункт урнашкан. Иң үзенчәлеклесе – 1000 нән азрак кеше яшәүче авылның беренче ярдәм күрсәтү үзәгендә кабул итү, процедура, балалар, хатын-кызлар бүлмәсеннән тыш, теш дәвалау бүлмәсе дә һәм теш табибы да бар.

«4 кеше эшлибез: мөдир, теш табибы, шәфкать туташы һәм җыештыручы. Система да куябыз, тешне дә дәвалыйбыз», – дип көлешәләр. Әмма медпунктның мөдире Венера апа: «Эшкә килергә теләүче яшьләр тезелеп тормый, безгә пенсия белән бергә хезмәт хакыбыз җитәдер, ләкин алар 25-30 меңгә бик риза түгел шул», – ди...

Мазарбаш авылында урнашкан Җәмигъ мәчетенең бик кызыклы тарихы бар. Мәчетнең үзенә 1807 елда нигез салына башлый һәм 1829 елда ачыла. «1934 елны мәчетебезне ябарга дигән карар чыгарыла. Ул шулкадәр биек, хәтта манарага менеп, күршедәге Иләт авылының чиркәвен күреп булган. 1935 елны манарасын кисеп төшерәләр. Үзебезнең авыл халкының манараны кисәргә кулы күтәрелми, читтән килгән кешеләр кисә. Манара киселгәч, Гаяз абый Әсәпов бер бакчага барып төшкән айны таба да яшереп куя. Аны милиция дә, халык та эзли, әмма таба алмый. Айның юкка чыгу сәбәбен, «Аллаһы Тәгалә үзенә алган» дип аңлаталар. Еллар узганнан соң, Гаяз абыйның балаларыннан сорашып йөри торгач, гаражны сүткән вакытта ай килеп чыга», – ди Рәис Сәлихов.

Мәчетнең имам-хатыйбы – Әхмәд хәзрәт Вәгыйзов. «Мәчетебездә барлык уңайлыклар да тудырылган, 2 тәһарәтханә бар. Балалар, өлкәннәр өчен дә дини дәресләр алып барыла. Ләкин шундый зур мәчетне карап торучыларга һәм биредә эшләүчеләргә хезмәт хакы каралмаган. Бары тик җыештыручыга гына мин аена 4 мең түлим», – ди ул.

Мәчеттән ерак түгел, кабер ташларын язучы һәм чардуганнар ясаучы Данис Мөхәммәтҗановның остаханәсе урнашкан иде. Ул үзен төрле өлкәләрдә сынап карый: агроном да, авыл башлыгы да, итче дә, тимерче дә, бераз рәссам да булырга туры килә аңа.

«Чардуганның бәясе бизәкләрнең авырлыгына бәйле, менә бу чардуганның бәясе 30 мең. Минем 14 мең материалга гына китә – тимергә, буяуга. Һәм 16 меңен башкарган эш өчен алам. Ташлар шулай ук төрлечә бәядә бара: 5 меңгә, 4 мең 300 гә, 3 мең 500 гә вариантлар бар», – диде Д.Мөхәммәтҗанов.

Ниһаять, сәфәребезнең соңгы ноктасы – Гайнан Кормаш исемендәге Куян мәктәбе. Җырлап, коймаклар белән каршы алган булсалар, җырлап-биеп, бал-май һәм казылыклар белән сыйлап озаттылар.

Камилә БИЛАЛОВА.

Салават КАМАЛЕТДИНОВ *фотолары.*

Уңышка ирешү сере

Күкрәк сөтен имеп үскән сабыйларның киләчәктә югары социаль статуска ирешү һәм баш әйләндергеч карьера ясау ихтималы зуррак. 34 мең кешенең социаль күрсәткечләрен һәм интеллектуаль сәләтен тикшергән Лондон университеты көллияте галимнәре шундый фикергә килгән. Тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, күкрәк сөтен имезеп үстерү социаль үсеш ихтималын 24 процентка арттыра һәм тормыш баскычыннан аска тәгәрәү ихтималын 20 процентка киметә икән. Күкрәк сөте балаларның неврологик үсешен яхшырта, бу исә аларның акыл сәләтенә уңай тәэсир итә. Имезеп үстерелгән баланың стрессларга бирешү ихтималы да кимрәк, чөнки ул ашаганда әнисе белән тыгыз бәйләнешкә керә һәм тынычлана. Күкрәк сөте баланың баш миенә тизрәк үсәргә дә булыша. Кимендә 3 ай гына булса да имезелгән сабыйның баш миендә сөйләм, эмоцияләр һәм танып-белү сәләтенә җаваплы зоналар 2 яшькә җиткәндә күбрәк үсешкә ирешкән була.

(“Daily Mail”).

Кактус сакламый

Компьютеры янына кактус куймаган бухгалтер яки башка офис хезмәткәре юк иде ул берзаман – янәсе, әлеге чәнечкеле үсемлек нурланыштан сакларга сәләтле. Физика дәреслеген ачып караган теләсә кемгә мәгълүм югыйсә: яктылыкны “йота” торган бернәрсә белән дә бүлмәне караңгылатып булмаган кебек, күренмәс нурланышны да сеңдереп булмый. Әлеге мифны үзгәртеп кору чорында студент-физиклар (шул исәптән Алекс Янг) тараткан. Алар кактусның саклагыч үзлекләре турында псевдомәкалә язган һәм төрле редакцияләргә җибәргән. Язманы бөтен җирдән диярлек ачуланып кире борганнар, бары тик “Работница” журналы гына чынга алган һәм бастырган. Шул вакыттан бирле әлеге миф газета-журналларның берсеннән икенчесенә күчеп һаман яши.

(“Лента.ру”).

Йөз тапкыр тирәнәйгән

1980 елның 24 ноябрендә нефть эзләгәндә, Американың Пенёр күлендә борау ялгыш астагы тоз шахталарының берсенә кереп китә. 35 сантиметрлы тишекне тиз арада зурайтып, су аска ыргыла. Күл бик тиз саега, аннары аңа үзен Мексика култыгы белән тоташтырган каналдан океан суы ага башлый. Тиз арада ул төче сулыктан тозлы сулы күлгә әйләнә, йөз тапкырга тирәнәя, соңрак инде әйләнә-тирәдәге бөтен экосистема да тулысынча үзгәрә.

(“The Local”).

Вакыт алмашу сызыгы

Әлеге шартлы сызык Тын океандагы 180 нче меридиан буенча үтә. Вакыт алмашу сызыгын көнбатыштан көнчыгышка кичеп чыкканда, 24 сәгатькә кирегә – “кичә”гә, ә мәшрикътән мәгърибкә кичкәндә, бер тәүлеккә алга – “иртәгә”гә күчеп була. Бу – планетада вакыт иң тиз үтә торган урын. Ике утрауны диңгездәге дүрт километр ара аера, гади моторлы көймәдә әлеге араны 15-20 минутта үтеп була кебек. Әмма Гринвич буенча утрауларны нәкъ 21 сәгать аера: мәсәлән, әгәр Ратманов утравында пәнҗешәмбенең өйләсе икән, Крузенштерн утравында әле чәршәмбе, кичке сәгать 3 кенә.

(“The Mirror”).

Кайсы башлырак?

Америкадагы Вандербильт университеты галимнәре озак еллар буе үткәргән тикшеренү этнең баш мие кабыгындагы нейроннар санының мәченекенә караганда икеләтә артыграк булуын күрсәткән. Эт миенең фикерләү һәм планлаштыру өчен җавап бирә торган өлешендә якынча 530 миллион, мәченекендә 250 миллион нейрон бар икән. Экспертлар фикеренчә, хайваннарның, булган тәҗрибәләрен истә тотып, нәтиҗә ясау сәләте нәкъ менә нейроннар санына бәйле. Чагыштыру өчен кеше миендәге нейроннар саны да китерелә – алар якынча 16 миллиард тәшкил итә. Нейробиолог Сюзанна Геркулано-Хоузель фикеренчә, мәчеләрне дә акылсыз хайван дип әйтеп булмый, әмма маэмайлар катлаулырак бурычларны хәл итәргә сәләтле. Проект кысаларында галимнәр аю, янут, мангуст, сыртлан, арыслан һәм сасы көзәннәрнең дә баш миен өйрәнгән. Янут миендәге нейроннар саны да этнеке кадәр икәне ачыкланган.

(“The Washington Times”).

Ак аюдан күрмәкче...

Ак аю кытайларны кешене туңдырмый торган кием тегүгә илһамландырган. Әлеге хайван йонындагы төкләрнең эче куыш, шунлыктан алар бөтен җылыны аю тәнендә сакларга мөмкинлек бирә. Төкләр сыгылмалы, тартылучан һәм су сеңдерми. Әлеге феноменны тәфсилләп өйрәнеп, Кытай Фән һәм технологияләр университеты тикшеренүчеләре үзлекләре буенча хәтта чын аю тиресеннән дә җылырак материал ясаган. Аның нигезен нечкә теллур җеп тәшкил итә. Галимнәр теллурны углеродлы наночыбыкка сеңдергән, соңрак химик реагент ярдәмендә наночыбык эретелгән дә, шул рәвешле структурасы ак аю төгенә охшаган эче куыш миллионлаган көпшә барлыкка килгән. Әлеге көпшәләр изоляцияли торган аэрогель ясарлык җепсыман структурага әйләндерелгән. Нәтиҗәдә бик җиңел һәм бик җылы материал пәйда булган. Әмма аны күпләп җитештерү турында әлегә сүз дә булу мөмкин түгел, чөнки теллур – бик кыйбатлы металл. Хәзер галимнәр аны алыштырырлык арзанлы матдә эзли.

(“Der Spiegel”).

Ак әхрам

